Вятка губернасы Сарапул өязенең (хәзер Татарстан Республикасының Әгерҗе районы) Иж-Бубый авылында Бубый мәдрәсәсе нигезләнүгә 240 ел (1781)
– 240 лет назад основано медресе Буби в дер. Иж-Бобья Сарапульского уезда Вятской губернии (ныне Агрызский район Республики Татарстан) (1781) (См.: Татарстан: Истәлекле һәм онытылмас даталар календаре=Календарь знаменательных и памятных дат. 2011. – Казань: Милли китап, 2010. – С. 128–131)



*Бертуган Бубыйлар йорты һәм хатын- кызлар мәдрәсәсе. Иж-Бубый авылы. 1908 – 1910 еллар*



Казанда беренче рус театры ачылуга 230 ел (1791; хәзер В.И.Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры)

– 230 лет назад в Казани открылся первый русский театр (1791; сейчас Казанский академический русский Большой драматический театр им. В.И.Качалова; см.: Татарстан: Истәлекле һәм онытылмас даталар календаре=Календарь знаменательных и памятных дат. 2011. – Казань: Милли китап, 2010. – С. 132–136)

Педагог, төрки телләр белгече Салихҗан Бикташ улы Кукляшевның тууына 210 ел (1811–1864)

– 210 лет назад родился педагог, языковед Салихджан Бикташевич Кукляшев (1811–1864; см.: Татарстан: Истәлекле һәм онытылмас даталар календаре=Календарь знаменательных и памятных дат. 2011. – Казань: Милли китап, 2010. – С. 137–139)

Архитектор Павел Алексеевич Солнцевның тууына 200 ел (1821–1875)

– 200 лет назад родился архитектор Павел Алексеевич Солнцев (1821–1875)

«Казанский вестник» («Казан хәбәрчесе») дип аталган айлык әдәби журнал чыга башлауга 200 ел (1821–1833)

– 200 лет ежемесячному литературному журналу «Казанский вестник» (1821–1833)

Архитектор Александр Андреевич Болотовның тууына 180 ел (1841–1884)

– 180 лет назад родился архитектор Александр Андреевич Болотов (1841–1884)

180 ел элек Казанда мәгърифәтче Р.Әмирханов тарафыннан беренче басма татар календаре «Горрәлек» чыга (1841)

– 180 лет назад просветитель Р.Амирханов в Казани начал издавать первый татарский календарь «Горрэлек» (1841)

Казандагы «Урак һәм чүкеч» заводы нигезләнүгә 170 ел (1851)

– 170 лет назад в Казани основан завод «Серп и молот» (1851)

Архитектор, инженер Иван Никитич Колмаковның тууына 160 ел (1861–1908)

– 160 лет назад родился архитектор, инженер Иван Никитич Колмаков (1861–1908)

Педагог, дин галиме Габдулла Габделгалләм улы Бубый (Нигъмәтуллин)ның тууына 150 ел (1871–1922)

– 150 лет назад родился педагог, богослов Габдулла Габделгаллямович Буби (Нигматуллин) (1871–1922)

Архитектор Михаил Степанович Григорьевның тууына 140 ел (1881–1933)

– 140 лет назад родился архитектор Михаил Степанович Григорьев (1881–1933)

Язучы, педагог Хәбибрахман Габделвәли улы Зәбиринең (Зәбировның, псевдонимы – Чистапули) тууына 140 ел (1881–1942)

– 140 лет назад родился писатель, педагог Хабибрахман Габдельвалиевич Забири (Забирова, псевд. – Чистапули; 1881–1942)

Педагог, гарәп теле белгече, гарәпчә-татарча сүзлек авторы Таһир Әхмәтҗан улы Ильясиның тууына 140 ел (1881–1933)

– 140 лет назад родился педагог, арабист, автор арабско-татарского словаря Тахир Ахметзянович Ильяси (1881–1933)

Актёр, театр эшлеклесе Локман Мөхәммәтхан улы Аитовның тууына 130 ел (1891–1972)

– 130 лет назад родился актёр, театральный деятель Лукман Мухамметханович Аитов (1891–1972)

Язучы-прозаик, тәрҗемәче, публицист Садри Җәләлнең (Садретдин Хәйретдин улы Вәлидовның) тууына 130 ел (1891–1943)

– 130 лет назад родился писатель, переводчик, публицист Садри Джалял (Садритдин Хайрутдинович Валидов; 1891–1943) (См.: Татарстан: Истәлекле һәм онытылмас даталар календаре=Календарь знаменательных и памятных дат. 2016. – Казань: Милли китап, 2015. – С. 133–136)

Педагог, журналист, пьесалар һәм хикәяләр авторы Габделхәй Ишмөхәммәт улы Динмөхәммәтовның тууына 130 ел (1891–1922)

– 130 лет назад родился педагог, журналист, автор пьес и рассказов Габдулхай Ишмухаметович Динмухаметов (1891–1922)

Актёр Гыйләҗетдин Ибраһим улы Ибраһимов (Казанский)ның тууына 130 ел (1891–1938)

– 130 лет назад родился актёр Гилязетдин Ибрагимович Ибрагимов (Казанский; 1891–1938)

Мәскәү-Казан тимер юлы төзелә башлауга 130 ел (1891–1893)

– 130 лет назад началось строительство Московско-Казанской железной дороги (1891–1893)

Шагыйрь Ярлы Кәримнең (Габдулла Әхмәтвәли улы Кәримовның) тууына 120 ел (1901–1937)

– 120 лет назад родился поэт Ярлы Карим (Габдулла Ахметвалеевич Каримов; 1901–1937)

Актриса Рокыя Камалетдин кызы Кушловскаяның тууына 120 ел (1901–1986)

– 120 лет назад родилась актриса Рукия Камалетдиновна Кушловская (1901–1986)

Актёр Хәсән Кәтиевнең тууына 120 ел (1901–1943)

– 120 лет назад родился актёр Хасан Катеев (1901–1943)

«Победа» химия лабораториясе приборлары һәм пыяла савыт-саба заводы төзелүгә 120 ел (1901). Яшел Үзән районының Васильево посёлогында урнашкан

– 120 лет заводу химико-лабораторных приборов и посуды «Победа» (1901). Расположен в посёлке Васильево Зеленодольского района РТ

График, рәссам Григорий Яковлевич Поляковның тууына 120 ел (1901–1948)

– 120 лет назад родился график и живописец Григорий Яковлевич Поляков (1901–1948)

Лубян урман хуҗалыгы техникумы (колледжы) ачылуга 100 ел (1921)

– 100 лет Лубянскому лесотехническому техникуму (колледжу) (1921)

Казан медицина инструментлары заводы төзелүгә 80 ел (1941)

– 80 лет Казанскому медико-инструментальному заводу (1941)

Татарстан Республикасының Дәүләт симфоник оркестры оештырылуга 55 ел (1966)

– 55 лет Государственному симфоническому оркестру Республики Татарстан (1966)



30 ел элек Татарстан Республикасының Балтач районы Шода авылында М.Фәйзинең әдәби музей-йорты ачыла (1991)

– 30 лет назад в с. Шуда Балтасинского района Республики Татарстан открыт Литературный музей-усадьба им. М.Файзи (1991)

## ТҮБӘНДӘ ИСЕМНӘРЕ КҮРСӘТЕЛГӘН ЯКТАШЛАРЫБЫЗ – СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЙЛАРЫНЫҢ 2021 ЕЛДА ЮБИЛЕЙЛАРЫ БУЛА:*

## В 2021 ГОДУ ИСПОЛНЯЕТСЯ ГЕРОЯМ СОВЕТСКОГО СОЮЗА – НАШИМ ЗЕМЛЯКАМ:**

Зариф Закир улы Алимовның тууына 100 ел (1921–1945)

– 100 лет со дня рождения Зарифа Закировича Алимова (1921–1945)

Александр Максимович Беркутовның тууына 110 ел (11.11.1911–1962)

– 110 лет со дня рождения Александра Максимовича Беркутова (11.11.1921–1962)

Василий Галләм улы Булатовның тууына 100 ел (15.09.1921–1988)

– 100 лет со дня рождения Василия Галлямовича Булатова (15.09.1921–1988)

Александр Григорьевич Васильченконың тууына 110 ел (23.11.1911–1960)

– 110 лет со дня рождения Александра Григорьевича Васильченко (23.11.1911–1960)

Василий Николаевич Гордовның тууына 125 ел (12.12.1896–1950)

– 125 лет со дня рождения Василия Николаевича Гордова (12.12.1896–1950)

Виктор Антонович Григорьевның туусына 100 ел (18.08.1921– 1985)

– 100 лет со дня рождения Виктора Антоновича Григорьева (18.08.1921–1985)

Фәхретдин Гыйльметдин улы Заһидуллинның туусына 110 ел (1911–1998)

– 110 лет со дня рождения Фахрутдина Гильмутдиновича Загидуллина (1911–1998)

Геннадий Михайлович Захаровның туусына 100 ел (25.10.1921–1969)

– 100 лет со дня рождения Геннадия Михайловича Захарова (25.10.1921–1969)

Степан Игнатьевич Козловның туусына 100 ел (1921–1945)

– 100 лет со дня рождения Степана Игнатьевича Козлова (1921–1945)

Иван Егорович Кочневның туусына 100 ел (15.09.1921–1958)

– 100 лет со дня рождения Ивана Егоровича Кочнева (15.09.1921–1958)

Николай Михайлович Кошаевның туусына 110 ел (22.05.1911–1976)

– 110 лет со дня рождения Николая Михайловича Кошаева (22.05.1911–1976)

Сәхип Нурлыгаян улы Майскийның туусына 120 ел (17.01.1901–1942)

– 120 лет со дня рождения Сахиба Нурлугаяновича Майского (17.01.1901–1942)

Илдар Мәннан улы Мәннановның тууына 100 ел (10.03.1921–2010)

– 100 лет со дня рождения Ильдара Маннановича Маннанова (10.03.1921–2010)

Владимир Николаевич Николаевның тууына 100 ел (09.02.1921–1944)

– 100 лет со дня рождения Владимира Николаевича Николаева (09.02.1921–1944)

Нәкыйп Сафа улы Сафинның тууына 100 ел (15.03.1921–1987)

– 100 лет со дня рождения Накипа Сафиевича Сафина (15.03.1921–1987)

Зәки Хәбибулла улы Хәбибуллинның тууына 110 ел (28.07.1911–1945)

– 110 лет со дня рождения Заки Хабибулловича Хабибуллина (28.07.1911–1945)

Фатих Зариф улы Шәриповның тууына 100 ел (20.01.1921–1995)

– 100 лет со дня рождения Фатыха Зариповича Шарипова (20.01.1921–1995)

Пётр Григорьевич Шафрановның тууына 120 ел (09.01.1901–1972)

– 120 лет со дня рождения Петра Григорьевича Шафранова (09.01.1901–1972)

---

***Геройларның тормыш юллары турындагы очеркларны кара:**

Батырлар китабы= Книга Героев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 395 б.

Советлар Союзы Геройлары – якташларыбыз. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 680 б.

Ханин Л. Советлар Союзы Геройлары – Татарстан уллары. – Казан: Татар. китап нәшр., 1966. – 640 б.




****Очерки о жизненном пути Героев см.:**

Герои Советского Союза – наши земляки: сб. докум. очерков и зарисовок в 3-х кн. /сост. З.И.Гильманов, А.К.Айнутдинов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1982–1985.

Ханин Л. Герои Советского Союза – сыны Татарии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1963. – 680 с.

Герои Казани = Казан Каһарманнары /авт.-сост.: М.В.Черепанов, Е.В.Панов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2018. – 335 с. илл.



## ТҮБӘНДӘ ИСЕМНӘРЕ КҮРСӘТЕЛГӘН ЯКТАШЛАРЫБЫЗ – СОЦИАЛИСТИК ХЕЗМӘТ ГЕРОЙЛАРЫНЫҢ 2021 ЕЛДА ЮБИЛЕЙЛАРЫ БУЛА:*

## В 2021 ГОДУ ИСПОЛНЯЕТСЯ ГЕРОЯМ СОЦИАЛИСТИЧЕСКОГО ТРУДА – НАШИМ ЗЕМЛЯКАМ:*

Алмас Харис улы Булатовның тууына 90 ел (02.05.1931–1989)

– 90 лет со дня рождения Алмаса Харисовича Булатова (02.05.1931–1989)

Ришат Тимергали улы Булгаковның тууына 90 ел (06.06.1931– 1989)

– 90 лет со дня рождения Ришата Тимергалиевича Булгакова (06.06.1931–1989)

Гайфетдин Сәлахетдин улы Галиевнең тууына 110 ел (18.11.1911–1996)

– 110 лет со дня рождения Гайфутдина Салахутдиновича Галеева (18.11.1911–1996)

Әсгать Гариф улы Гариповның тууына 100 ел (15.01.1921–2001)

– 100 лет со дня рождения Асгата Гариповича Гарипова (15.01.1921–2001)

Нәҗип Гаяз улы Җиһановның тууына 110 ел (02.01.1911–1988)

– 110 лет лет со дня рождения Назиба Гаязовича Жиганова (02.01.1911–1988)

Нәсифулла Гыйззәтулла улы Зәйнуллинның тууына 90 ел (28.10.1931–1981)

– 90 лет со дня рождения Насифуллы Гизатулловича Зайнуллина (28.10.1931–1981)

Николай Иванович Максимовның тууына 110 ел (19.05.1911–1967)

– 110 лет со дня рождения Николая Ивановича Максимова (19.05.1911–1967)

Семён Павлович Никитинның тууына 100 ел (15.02.1921–1968)

– 100 лет со дня рождения Семёна Павловича Никитина (15.02.1921–1968)

Зәйнәп Садыйк кызы Садыйкованың тууына 100 ел (09.01.1921–1977)

– 100 лет со дня рождения Зайнаб Садыковны Садыковой (09.01.1921–1977)

Александр Осипович Седовның тууына 110 лет (15.08.1911–1999)

– 110 лет со дня рождения Александра Осиповича Седова (15.08.1911–1999)

Андрей Алексеевич Трофимукның тууына 110 ел (03.08.1911–1999)

– 110 лет со дня рождения Андрея Алексеевича Трофимука (03.08.1911–1999)

Николай Андрианович Тюнинның тууына 90 ел (03.09.1931–1995)

– 90 лет со дня рождения Николая Андриановича Тюнина (03.09.1931–1995)

Николай Васильевич Фроловка 90 яшь (13.12.1931)

– 90 лет Николаю Васильевичу Фролову (13.12.1931)

Мәгъсүм Шәйгазам улы Хөсәеновның тууына 110 ел (15.08.1911–1986)

– 110 со дня рождения Магсума Шайгазамовича Хусаинова (15.08.1911–1986)

Камил Фаяз улы Шакировның тууына 90 ел (15.08.1931–2005)

– 90 лет со дня рождения Камиля Фаязовича Шакирова (15.08.1931–2005)

---

*** Геройларның тормыш юллары турындагы очеркларны кара:**

**Очерки о жизненном пути Героев см.:**

Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы – наши земляки = Социалистик Хезмәт Геройлары һәм Хезмәт даны орденының тулы кавалерлары – безнең якташларыбыз. – Казань, 2003. – 232 с. – На рус. и татар. яз.

Герои Труда Татарии 1920–1938 гг.: док. очерки. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. – 304 с.

Герои Социалистического Труда (1938–1978 гг.): (док. очерки). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. – 383 с.

Герои Социалистического Труда Татарии: док. очерки. Кн.2. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 352 с.

# БЕЛЕШМӘ-БИБЛИОГРАФИК МӘГЪЛҮМАТЛАР

# СПРАВОЧНО-БИБЛИОГРАФИЧЕСКИЕ СВЕДЕНИЯ





**28** февраль/февраля



**Геннадий Паушкин**
1921–2007

тууына 100 ел
100 лет со дня рождения

Фронтовик-язучы Геннадий Александрович Паушкин 1921 елның 28 февралендә Казанда эшче гаиләсендә туа. 1939 елда Казан университетының тарих факультетына укырга керә. Шул ук елны, укуын туктатып, үзе теләп фин сугышының чик буе гаскәрләренә китә.

1941 елның июленнән Г.Паушкин – Бөек Ватан сугышы фронтларында. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Байрак орденнары, медальләр белән бүләкләнә.

Демобилизациядән соң Г.Паушкин Казан университетында укуын дәвам итә, бер үк вакытта «Комсомолец Татарии» газетасы редакциясендә әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли. 1953–1955 елларда өч республика – Татарстан, Чуаш һәм Мари АССРда «Комсомольская правда» газетасының махсус хәбәрчесе була.

1950 нче еллар ахырыннан Г.Паушкин «Әдәби Татарстан» («Литературный Татарстан») альманахы мөхәррире, 1955–1965 елларда ТАССР Язучылар берлегенең рус секциясе консультанты. Ул – 1957 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

Беренче шигырьләре армия һәм фронт газеталарында басыла башлый.

«Һәрвакыт юлда» («Всегда в пути», 1954) «Туган яклар» («Родные просторы», 1958) исемле җыентыкларга кергән

шигырьләре – «фронт юллары җырлары», алар Ватанга, хатын-кызга, табигатькә лирик мәхәббәтне белдерү турында.

«Ерактагы заставада» («На дальней заставе», 1952), «Кошлар китте» («Птицы улетели», 1962), «Элемтәгә чыгам» («Слушай мои позывные», 1965), «Йолдызлар сүнми» («Звезды не гаснут», 1967), «Кайтыгыз ләкләкләр» («Вернитесь аисты», 1970) исемле чәчмә әсәрләрендә Г.Паушкин солдатның хәрби батырлыгы темасына мөрәҗәгать итә. Ул – автобиографик жанрда язылган «Карлар тагын яуды» («И так же падал снег», 1981), «Томалану» («Затмение», 1990) дигән әсәрләр циклы, туган җир турында повесть һәм хикәяләр, Татарстан төзүчеләре һәм нефтьчеләре турында очерклар авторы да.

Г.Паушкин Х.Туфан, А.Расих һ.б. әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итә.

1981 елда Г.А. Паушкинга ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелә.

Геннадий Александрович Паушкин 2007 елның 15 октябрендә вафат була.



Писатель-фронтовик Геннадий Александрович Паушкин родился 28 февраля 1921 года в Казани в семье рабочего. В 1939 году поступает на исторический факультет Казанского университета. В том же году, прервав учёбу, уходит добровольцем на финскую войну в пограничные войска.



*Г. Паушкин – полковой поэт (1941 г.)*

С июля 1941 года Г.Паушкин – на фронтах Великой Отечественной войны. Награждён орденами Отечественной войны 2-й степени, Красной Звезды и медалями.

После демобилизации Г.Паушкин продолжает учёбу в Казанском университете, совмещая её с работой в качестве заведующего отделом литературы и искусства в редакции газеты «Комсомолец Татарии». В 1953–1955 годы – собственный корреспондент «Комсомольской правды» в Татарской, Чувашской и Марийской АССР.

С конца 1950-х годов Г.Паушкин работает редактором альманаха «Литературный Татарстан», в 1955–1965 годы – литературным консультантом русской секции Союза писателей ТАССР. С 1957 года является членом Союза писателей СССР.



*Г. Паушкин среди однополчан*

Первые его стихотворения были опубликованы на страницах армейских и фронтовых газет. Стихотворения, вошедшие в сборники «Всегда в пути» (1954), «Родные просторы» (1958), «Возвращение» (2004) – это «песни фронтовых дорог», лирические признания в любви Родине, женщине, природе.

В прозаических произведениях («На дальней заставе», 1952; «Птицы улетели», 1962; «Слушай мои позывные», 1965; «Звёзды не гаснут», 1967; «Вернитесь, аисты», 1970) Г.Паушкин обращается к теме подвига и мужества рядовых солдат. Поэт является автором цикла произведений автобиографического жанра («И так же падал снег», 1981; «Затмение», 1990), повестей и рассказов о родной земле, очерков о строителях и нефтяниках Татарстана. Г.Паушкин перевёл на русский язык произведения Х.Туфана, А.Расиха и др.

В 1981 году Г.А.Паушкину присвоено почетное звание заслуженного работника культуры ТАССР.

Геннадий Александрович Паушкин умер 15 октября 2007 года.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Паушкин Г.** Кайтыгыз, ләкләкләр: повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 67 б.

**Паушкин Г.** Слушай мои позывные!: повесть и рассказы. – М.: Современник, 1978. – 191 с.

**Паушкин Г.** И так же падал снег: повести и рассказы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1981. – 351 с.

**Паушкин Г.** Пришельцы: повесть. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 111 с.

**Паушкин Г.** Позабыть нельзя: повесть. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – 80 с.

**Паушкин Г.** Затмение: повесть, рассказ, очерки. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. – 158 с.: ил.

**Паушкин Г.** Трава на камне: повести. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. – 366 с.

**Паушкин Г.** Материнская звезда: избранные рассказы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1996. – 160 с.

**Паушкин Г.** Живу и помню: повести и рассказы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2001. – 240 с.

**Паушкин Г.** Возвращение: тетрадь, найденный в окопе: стихи /[предисл. Н.Корсакова]. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. – 64 с.: портр.

**Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б.** Совет Татарстаны язучылары: биобиблиогр. белешмә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б. 368–370.

**Сидоров С.** Геннадий Паушкинга 60 яшь //Казан утлары. – 1981. – № 2. – Б. 185–187.

**Скороходов М.** Утта чыныккан каләм //Соц. Татарстан. – 1981. – 28 февр.

**Гиниятуллина А.** Писатели Советского Татарстана: биобиблиогр. справочник. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – С. 331–332.

**Кутуй Р.** И слово обретёт голос // Республика Татарстан. – 1996. – 24 февр.

**Кутуева Я.** Слышу твои позывные // Казань. – 2000. – № 5. – С. 66–67.

**Хабибуллин М.** Философия сердца и разума //Респ. Татарстан. – 2001. – 27 февр. – С. 7.

**Газизова Л.** Новые лауреаты Горьковской премии: лауреаты премии – 2004 //Республика Татарстан. – 2004. – 30 мая.

**Газизова Л.** Из поколения победителей //Респ. Татарстан. – 2006. – 28 февр.

**Мустафин Р.** Слушая его позывные //Татарстан. – 2006. – № 3. – С. 62.

**Ганеева А.** Когда плачет небо //Молодежь Татарстана. – 2007. – 19 окт. – С. 7.

**Корсакова Н.** Найденная в старых окопах: [конкурс «Разные дни войны». Об истории тетрадки, найденной в старом окопе под Одессой, в которой были поэма и 80 стихов за подписью Геннадия Паушкина] // Казанские ведомости. – 2000. – 1 февр. – С. 4.

**Хузеева Л.** О них будут слагать легенды: [фонд Центр. гос. архива РТ пополнился фронтовыми письмами писателя Геннадия Паушкина] // Респ. Татарстан. – 2009. – 20 июня.

**25** апрель/апреля



**Әдһәм Рәхим улы Тенишев**
**Эдхям Рахимович Тенишев**
1921—2004

тууына 100 ел
100 лет со дня рождения

Тел галиме-тюрколог Әдһәм Рәхим улы Тенишев 1921 елның 25 апрелендә Пенза шәһәрендә зыялы татар гаиләсендә туа. Тенишевлар нәселе – борынгы татар морзалары.

1938 елда Ә.Тенишев Мәскәүдәге транспорт инженерлары әзерли торган институтка укырга керә. Бөек Ватан сугышы тәмамлангач, Ленинград дәүләт университетының шәрык факультетында укый һәм шушы вакыттан аның көнчыгыш белгече, тюрколог буларак эшчәнлеге башлана.

1953 елда ул борынгы уйгур эпосы «Алтын Ярук» буенча кандидатлык диссертациясен яклый. 1954 елда Ә.Р.Тенишев Мәскәүгә күченеп килә һәм СССР Фәннәр академиясе Тел белеме институтының төрки телләр секторында эшли башлый.

1956–1958 елларда, бу ил территориясендә төрки телләрне өйрәнү һәм аларның диалектлары буенча материал туплауда ярдәм күрсәтү максаты белән, Кытай Халык Республикасының Фәннәр академиясенә командировкага җибәрелә.






1969 елда Ә.Р.Тенишев докторлык диссертациясен яклый. 1970–2004 елларда үзенең төп хезмәтләрен бастырып чыгара. Ә.Р.Тенишев борынгы төрки телләрнең Үзәк Азия халыклары телләре берлегенә караулары белән бәйле үзенчәлекләрен тикшерүгә зур өлеш кертә. Төрки әдәби телләрнең Орхон-Енисей язма истәлекләреннән алып эзлекле үсеше схемасын төзи; татар әдәби теле тарихына аерым игътибар бирә. Галимнең теоретик нигезләмәләре тюркологиядәге яңа юнәлешкә – төрки әдәби телләрнең тарихи грамматикалары эшкәртмәләренә нигез була.

Ә.Р.Тенишев – СССР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы (1984), ТРның атказанган фән эшлеклесе (1997), Башкортстан Республикасы Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы (2001). Ул 15 китап, 200дән артык фәнни мәкалә бастырып чыгара.

Ә.Р.Тенишев 2004 елның 11 июлендә вафат була. Мәскәүнең Хованское зиратында җирләнә.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә Ә.Р.Тенишевның шәхси китапханәсеннән кайтарылган (хатыны Е.А. Тенишевадан 2010 елда алынган) бай тупланма саклана. Тупланмага тел гыйлеменең төрле юнәлешләренә караган 3000 гә якын китап һәм вакытлы матбугат басмалары керә. Бүлектә Ә.Р.Тенишевның тупланмасын өйрәнү, исәпкә алу, фәнни



эшкәртү буенча эш алып барыла. Бөтен нөсхәләр дә Милли китапханәнең традицион һәм электрон каталогларына теркәлгән.

Казанның бер урамына Э.Тенишев исеме бирелгән.




Языковед-тюрколог Эдхям Рахимович Тенишев родился 25 апреля 1921 года в Пензе в семье татарских интеллигентов, представителей старинного татарского дворянского рода Тенишевых.

В 1938 году Э.Тенишев поступает в Московский институт инженеров транспорта. После окончания Великой Отечественной войны поступает на восточный факультет Ленинградского государственного университета, с этого момента начинается его деятельность как востоковеда-тюрколога.

В 1953 году ученый защищает кандидатскую диссертацию по уйгурскому языку памятника «Сутра золотого блеска». В 1954 году Э.Р.Тенишев переезжает в Москву, где работает в секторе тюркских языков Института языкознания АН СССР.

В 1956–1958 годах Э.Тенишев находился в командировке в Академии наук Китайской Народной Республики, занимался сбором материала по тюркским языкам и их диалектам на территории этой страны.

В 1969 году Э.Р.Тенишев защищает докторскую диссертацию. В 1970–2004 годы издает свои главные труды. Э.Р.Тенишев вносит большой вклад в исследование особенностей тюркских языков центрально-азиатского региона. Ученый создаёт стройную схему последовательного развития тюркских литературных языков, начиная с памятников орхоно-енисейской письменности; изучает историю татарского литературного языка. Теоретические положения учёного положили начало нового направления в тюркологии – разработке исторических грамматик тюркских литературных языков.


ЦИК СССР
ЛЕНИНГРАДСКИЙ ИНСТИТУТ ЖИВЫХ ВОСТОЧНЫХ ЯЗЫКОВ
Из библиотеки Э.Р.Тенишева
7
В. Бартольд
ИСТОРИЯ
ИЗУЧЕНИЯ ВОСТОКА В ЕВРОПЕ И РОССИИ
ЛЕКЦИИ
ЧИТАННЫЕ В УНИВЕРСИТЕТЕ И В ЛЕНИНГРАДСКОМ ИНСТИТУТЕ ЖИВЫХ ВОСТОЧНЫХ ЯЗЫКОВ
ИЗДАНИЕ ВТОРОЕ
ЛЕНИНГРАД
1925

Э.Р.Тенишев – член-корреспондент АН СССР (1984), заслуженный деятель науки РТ (1997), почётный академик АН Республики Башкортостан (2001), автор 15 книг, более 200 научных публикаций.

Э.Р.Тенишев скончался 11 июля 2004 года, похоронен на Хованском кладбище в Москве.

В отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки РТ бережно хранится книжная коллекция из личной библиотеки Э.Р.Тенишева, приобретённая у супруги ученого Е.А.Тенишевой в 2010 году. Она насчитывает около 3000 экземпляров книг и периодических изданий по различным направлениям языкознания. В отделе ведётся работа по изучению, учёту, описанию и научной обработке документов из коллекции Э.Тенишева. Все материалы введены в учётные документы Национальной библиотеки РТ, отражены в традиционных и электронных библиотечных каталогах.

Одна из улиц в Казани названа именем Э.Тенишева.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Тенишев Э.Р.** Саларский язык /[Акад. наук СССР; Ин-т народов Азии]. – М.: Изд-во восточной литературы, 1963. – 56 с. – (Языки Зарубежного Востока и Азии). – Библиогр.: с. 54–55.

**Тенишев Э.Р.** Уйгурский диалектный словарь /Акад. наук СССР; Ин-т языкознания. – М.: Наука, 1990. – 200 с.

**Тенишев Э.Р.** Язык жёлтых уйгуров /Акад. наук СССР; Ин-т народов Азии. – М.: Наука, 1966. – 84 с.: ил. – Библиогр.: с. 82–83.

**Хәкимҗанов Ф.** Бай эрудицияле галим //Казан утлары. – 1981. – № 5. – Б. 184–185.

**Юсупов Р.** Тюркология даһие Әдһәм Тенишев //Мәдәни җомга. – 2014. – 28 март. – Б. 13.

**Низамов И.** Сагыну көчәя генә //Мәдәни җомга. – 2004. – 27 авг. – Б. 11, 12.

**Гарипова Ф.** Җәнабе Әдһәм Тенишев ядкарьләре //Шәһри Казан. – 2004. – 23 июль.

**Кирсанов В.И.** Крупный востоковед-тюрколог //Исследование языка древнеписьменных памятников / КФАН СССР; ИЯЛИ. – Казань, 1980. – С. 3–17.

**Дыбо А.В., Нуриева Ф.Ш.** Тенишев Эдхям Рахимович // Казанская лингвистическая школа. Кн. 1: Казанская тюркская лингвистическая школа. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. – С.270–275.

**Нуриева Ф., Курбатов Х.** Тенишев, Еники, Куприн – близкие родственники //Татарстан. – 2003. – № 8. – С. 46–48.

**Коллекция Э.Р.Тенишева** = Ә.Р.Тенишев коллекциясе = The E.R.Tenishev Collection //Национальная библиотека Республики Татарстан = Татарстан Республикасы Милли китапханәсе = The National Library of Republik of Tatarstan. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. – С. 260–271. – Текст парал. на рус., татар. и англ. яз.

**Ашнин Ф.Д.** Список трудов Э.Р.Тенишева (с указанием рецензий на них) и литературы о нём //Исследование языка древнеписьменных памятников / КФАН СССР; ИЯЛИ. – Казань, 1980. – С. 18–32.

**15** май/мая



**Фуад Вәлиев**
**Фуад Валеев**
1921—1984

тууына 100 ел
100 лет со дня рождения

Сәнгать белгече, архитектор Фуад Хәсән (Хөсәен) улы Вәлиев 1921 елның 15 маенда Мәскәү шәһәрендә туа. Аның әти-әнисе чыгышлары белән хәзерге Татарстан Республикасы Биектау районының Кече Кавал авылыннан була. Әтисе Мәскәүдә берничә фабрика һәм кибет тота. Мондый тәэмин ителгән (житеш) һәм шактый укымышлы гаиләдә Фуад яхшы тәрбия һәм белем ала. Әтисе төрмә һәм лагерьларда утыра, ә 1937 елда атып үтерелә.

1947 елда Киев төзелеш инженерлары институтын тәмамлагач, Ф.Вәлиев Казанга килә һәм 1947–1957 елларда «Татгипронефтьпроект» институтының архитектура-төзелеш бүлеге, 1957–1959 елларда ТАССР Министрлар Советы каршындагы Махсус фәнни-реставрация остаханәсенең фәнни бүлеге җитәкчесе булып эшли.

1959 елда профессор Н.И.Воробьёв Ф.Вәлиевне СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтына чакыра. Биредә ул эшли дә, аспирантурада да укый, ә 1966 елда тарих фәннәре кандидатлыгына диссертация яклый; тормышында иң мөһим булган фундаменталь фәнни хезмәт – «Татар милли орнаменты» монографиясен язуын дәвам итә; ул 1969 елда дөнья күрә.




1971 елда Ф.Вәлиев институттан китә һәм Мари политехника институтында укыта, архитектура кафедрасының доценты була. 1975 елда Йошкар-Олада татар халкының һәм аның ата-бабаларының сәнгатенә һәм архитектурасына багышланган ике монографиясен бастыра.

1981 елда Ф.Вәлиев Казанга кайта һәм шул елдан ТАССРның Көнкүреш хезмәте министрлыгында баш рәссам, 1982–1984 елларда ТАССР Җирле сәнәгать министрлыгында консультант (киңәшче) сыйфатында хезмәт итә.

Ф.Вәлиев – Идел буе республикаларында беренче сәнгать белеме докторы (1984), татар сәнгать белеменә нигез салучыларның берсе; татар халкының бизәлеш сәнгатен, Казан татарларының авыл йортлары архитектура-сәнгать бизәлешен, Урта Идел буйларының борынгы чорлары, Идел буе Болгар дәүләте, Казан ханлыгы сәнгатен өйрәнә. Татарстан авылларына һәм татарлар тупланып яшәгән төбәкләргә (Әстерхан өлкәсе, Касыйм шәһәре һ.б.) экспедицияләр оештыра. Һөнәри-сәнгать мәдәниятенең фәнни типологиясен төзи; татар халык сәнгатендәге туку, чигү, каюлы күн, зәркәнчелек, агачка һәм ташка уеп бизәк төшерү кебек традицион төрләрнең тарихи тамырларын һәм үсешен өйрәнә; татар сәнгатенең Болгар һәм Алтын Урда сәнгатьләре белән дәвамчан бәйләнешен дәлилли.

Ул Болгар тарих-архитектура саклаулыгындагы кайбер биналарның реставрацияләү һәм реконструкцияләү проектларын эшләүдә катнаша. Ф.Вәлиев – 1970 нче елларда Казан халык һөнәрләре комбинатында, Казан нәфис эшләнмәләр фабрикасында сувенирлар һәм халык сәнгате эшләнмәләре җитештерүне оештыручыларның берсе дә. Ул республикада музейлар эшен үстерүгә зур өлеш кертә. Экспедицияләр вакытында ул җыйган материаллар ТР Дәүләт сынлы сәнгать




музеенда, ТР Милли музеенда татар гамәли-бизәлеш сәнгате коллекцияләренең нигезе булып тора.

Татарның мәшһүр галиме Ф.Вәлиев 1984 елның 11 октябрендә вафат була. Казанда җирләнгән.

Искусствовед, архитектор Фуад Хасанович (Хусаинович) Валеев родился 15 мая 1921 года в Москве. Его родители были выходцами из деревни Малые Ковали современного Высокогорского района Республики Татарстан. Отец владел несколькими фабриками и магазинами в Москве. Детство Ф. Валеева прошло в обеспеченной семье, где он получает хорошее воспитание и образование. Его отец проходит тюрьмы и лагеря, а в 1937 году был расстрелян.

После окончания в 1947 году Киевского инженерно-строительного института Ф.Валеев переезжает в Казань и в 1947–1957 годах работает руководителем архитектурно-строительного отдела института «Татгипронефтьпроект», в 1957–1959 годах – возглавляет научный отдел Специализированных научно-реставрационных мастерских при Совете Министров ТАССР.

В 1959 году профессор Н.И.Воробьев приглашает Ф.Валеева в Институт языка, литературы и истории КФАН СССР. Здесь он работает и учится в аспирантуре, а в 1966 году защищает диссертацию на степень кандидата исторических наук; продолжает работать над фундаментальным научным трудом – монографией «Татарский национальный орнамент», изданной в 1969 году.

В 1971 году Ф.Валеев уходит из института и работает доцентом кафедры архитектуры Марийского политехнического института. В 1975 году в Йошкар-Оле выпускает две монографии, посвящённые искусству и архитектуре татарского народа и его предков.

В 1981 году Ф.Валеев возвращается в Казань и работает главным художником Министерства бытового обслуживания

ТАССР, в 1982–1984 годах – консультантом Министерства местной промышленности ТАССР.

Ф.Валеев – первый в Поволжье доктор искусствоведения (1984), один из основоположников татарского искусствоведения; исследователь татарского декоративного искусства, архитектурно-художественного оформления сельского жилища казанских татар; древнего искусства Среднего Поволжья, Волжской Булгарии, Казанского ханства. Осуществил ряд экспедиций по Татарстану и местам компактного проживания татар (Астраханская обл., г.Касимов и др.). Является автором научной типологии материально-художественной культуры; исследователем традиционных видов национального искусства – ткачества, вышивки, кожаной мозаики, ювелирного дела, керамики, резьбы по камню и дереву, доказавшим преемственную связь татарского искусства с булгарским и золотоордынским наследием.

Ученый принимает участие в разработке проектов реставрации и реконструкции ряда зданий Болгарского историко-архитектурного заповедника. Ф. Валеев – один из организаторов в 1970-е годы производства сувениров и изделий народного промысла на Казанском комбинате народных промыслов, Казанской фабрике художественных изделий. Ф. Валеев внёс вклад в развитие музейного дела в республике. Собранные им во время экспедиций материалы легли в основу коллекций татарского декоративно-прикладного искусства в Государственном музее изобразительного искусства РТ, Национальном музее РТ.

Ф.Х.Валеев скончался 11 октября 1984 года. Похоронен в Казани.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Валеев Ф.Х.** Орнамент казанских татар /АН СССР, ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1969. – 202 с.: ил.

**Валеев Ф.Х.** Архитектурно-декоративное искусство казанских татар: сельское жилище. – Йошкар-Ола: Марийск. кн. изд-во, 1975. – 92 с.: ил.

**Валеев Ф.** Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. – Йошкар-Ола: Марийск. кн. изд-во, 1975. – 216 с.: ил.

**Валеев Ф.Х.** Народное декоративное искусство Татарстана. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 188 с.: ил.

**Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф.** Древнее искусство Татарии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – 166 с.: ил.

**Валеев Ф.Х., Валеева Г.Ф.** Древнее искусство Татарстана. – 2-е изд., доп. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. – 104 с.

**Валеев Ф.Х.** Татарский народный орнамент. – Казань, 2002. – 294 с.: ил.

**Вәлиева-Сөләйманова Г.** Хакыйкатьнең татлы җимеше; **Тәрҗеманов Н.** Сәнгатькә сәяхәт; **Фәхретдинов Р.** Алтын тутыкмый; **Нигъмәтҗанов М.** Дустымның җылы иңе; **Абдуллин Р.** Бер йотым ирек; **Габәши Р.** Яшьлегебез мәгънәсе; **Ахунов Г.** Акыл иясе; **Шәмси С.** Ул сынмыйча китте //Казан. – 1996. – № 5–6. – Б. 4–15; 44–45; 46–48; 49–50; 51; 52–55; 56–57; 57–60.

**Фәхретдинов Р.** Хәтер //Казан утлары. – 1991 – № 6. – Б. 182–185.

**Фахрутдинов Р.Г.** Фуад Хасанович Валеев: страницы биографии и научной деятельности // Искусство и этнос: новые парадигмы. – Казань: Дом печати, 2002. – С. 4–12.

**Валеева-Сулейманова Г.** Золотое яблоко истины; **Фахрутдинов Р.** Золото не тускнеет; **Нигмедзянов М.** Тепло плеча друга; **Ахунов Г.** Разум, согласный с сердцем; **Габяши Р.** Пароль нашей молодости; **Шамси С.** Он ушёл непокорённым; **Абдуллин Р.** Глоток свободных // Казань. – 1995. – № 5–6. – С. 4–16; 52–54; 54–55; 56–57; 57–60; 61–63; 64.

**23** май/мая



**Гамил Афзал**
**Гамиль Афзал**
1921—2003

туына 100 ел
100 лет со дня рождения

Шагыйрь Гамил Афзал (Гамил Гыймазетдин улы Афзалов) 1921 елның 23 маенда Татарстан АССРның Актаныш волосте Минзәлә кантоны (хәзер Татарстанның Актаныш районы) Такталачык авылында тегермәнче гаиләсендә туа. Колхозлашу чорында аның әтисе, гаиләсе белән, Магнитогорск шәһәренә төзелешкә күчеп китәргә мәҗбүр була. Биредә Гамил 35 нче татар мәктәбендә укый. Мәктәптә укыган елларында ул әдәбият түгәрәгенә йөри, үзе дә каләм тибрәтә башлый. 1937 елда беренче шигыре басылып чыга.

Шул ук елда Троицк шәһәрендәге татар педагогия техникумына укырга керә. Каты авырып китеп, алга таба укуын туктата.

1940–1949 елларда Магнитогорскидагы Металлургия комбинатының механика цехында слесарь булып эшли, шигырьләр язуын дәвам иттерә, эшче яшьләрдән драма түгәрәге төзеп спектакльләр, концертлар куеп йөри, әдәби кичәләр оештыра.

1949 елда, сәламәтлеге начараю сәбәпле, заводтагы эшеннән китә. 1954 елда икенче группа инвалидлык ала һәм Башкортстанга, апасы янына китә.

1954–1964 елларда Г.Афзал Башкортстанның Калтасы районы Шәрип һәм Заболотский авылларында яши. Биредә




ул ныклап торып иҗатка кереп чума. 1955 елда «Совет әдәбияты» журналында шигырьләре басылып чыга. 1957 елда балалар өчен «Кар сулары» һәм 1958 елда зурлар өчен «Вөҗдан сүзе» исемле беренче ике китабы дөнья күрә. Шуннан соң шагыйрьнең бер-бер артлы шигырь җыентыклары басыла башлый, ул халык арасында киң танылa.

1958 елда Гамил Афзал Татарстан (СССР) Язучылар берлегенә алына.

1965 елдан ул Әлмәт шәһәрендә яши башлый.

1950–1960 нчы елларда Гамил Афзал күбрәк юмор-сатира жанрында актив эшли, җитмешенче еллардан башлап аның иҗатында фәлсәфи лирика өстенлек ала башлый. Шулай ук ул юмористик һәм сатирик рухта язылган хикәяләре белән дә танылa.

Г.Афзал – татар, башкорт һәм рус телләрендә басылган кырыкка якын китап авторы.

1977 елда «Айлы кичләр» шигъри җыентыгы һәм «Борылам да карыйм...» циклына кергән шигырьләре өчен Г.Афзал Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. 1985 елда аңа ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, 1992 елда Татарстан Республикасының халык шагыйре дигән мактаулы исемнәр бирелә.




Гамил Афзал 2003 елның 20 августында Әлмәт шәһәрендә вафат була.

Поэт Гамиль Афзал (Гамиль Гыймазетдинович Афзалов) родился 23 мая 1921 года в деревне




Такталачук Мензелинского кантона Актанышской волости Татарской АССР (ныне Актанышский район Татарстана) в семье сельского мельника. В период коллективизации его семья была вынуждена переехать на строительство в Магнитогорск. Здесь Гамиль учится в татарской школе №35. В школьные годы он посещает литературный кружок и пробует сочинять стихи. В 1937 году было опубликовано его первое стихотворение.

В том же году Гамиль поступает в Татарский педагогический техникум в Троицке, но по состоянию здоровья оставляет учебу.

С 1940 по 1949 годы Г.Афзал работает слесарем механического цеха на Магнитогорском металлургическом комбинате, продолжает писать стихи, организует драматические кружки из рабочей молодёжи, ставит спектакли, концерты, устраивает литературные вечера.

В 1949 году по состоянию здоровья уходит с завода. В 1954 году, получив инвалидность второй группы, переезжает в Башкирию к сестре.




В 1954–1964 годах Г.Афзал живёт в деревнях Шарипово и Заболотское Калтасинского района. Много пишет, занимается активной творческой деятельностью. В 1955 году журнал «Совет әдәбияты» публикует цикл его стихотворений. Друг за другом издаются первые два сборника его стихотворений: в 1957 году сборник для детей «Кар сулары» («Вешние воды») и в 1958 году – «Вөждан сүзе» («Слово совести»). С этого










момента начинается издание поэтических сборников поэта, его творчество приобретает широкую известность в народе.

В 1958 году Г.Афзала принимают в Союз писателей Татарстана (СССР).

С 1965 года он проживает в городе Альметьевске.

В 1950–1960-х годах Г.Афзал пишет в основном в юмористическом и сатирическом жанре. С 1970-х годов в его творчестве преобладает философская лирика.

Г.Афзал – автор около сорока книг, изданных на татарском, башкирском и русском языках.

В 1977 году за книгу избранных произведений «Лунные вечера» («Айлы кичләр») Г.Афзал был удостоен Государственной премии Татарстана им. Г.Тукая. В 1985 году ему присвоено почетное звание заслуженного работника культуры ТАССР, в 1992 году – народного поэта Республики Татарстан.

Гамиль Афзал скончался 20 августа 2003 года в городе Альметьевске.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Афзал Г.** Гомер кичүләре: шигырьләр /төз.-мөх-р, кереш сүз язучы Г.Гыйльманов. – Казан: Рухият, 2000. – 560 б.: портр., фото.

**Афзал Г.** Сайланма әсәрләр: өч томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.

Т.1: Лирика, юмор, сатира /кереш сүз язучы С.Хәким. – 383 б.: портр. б-н.

Т. 2: Юмор һәм сатира, лирика, публицистика. – 335 б.

Т. 3: Юмор, сатира: балалар өчен шигырьләр. – 351 б.

Афзал Г. Рәхмәт!: лирика, юмор, сатира /кереш сүз язучы Л.Шәех. – Казан: Рухият, 2009. – 287 б.: портр. б-н.

**Афзал Г.** Үз туксаным туксан: юмор, сатира / төз. Л.Шәех. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 527 б.: портр. б-н.

**Афзал Г.** В строю: стихотворения: пер. с татар. – М.: Сов. писатель, 1960. – 107 с.

**Афзал Г.** Бессонной ночью: стихи / пер. с татар. А.Кафанова, А.Зайца. – М.: Сов. писатель, 1966. – 68 с.

**Афзал Г.** Песни вечной любви: избранные произведения / пер. с татар. М.Сафина. – Наб. Челны: Автограф, 2016. – 72 с.: портр.

**Әдипләребез:** биобиблиогр. белешмәлек. 2 томда. Т. 1 / [төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 751 б. – Гамил Афзал. – Б. 50–52.

**Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б.** Совет Татарстаны язучылары: биобиблиогр. белешмәлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 639 б. – Гамил Афзал. – Б. 19–21.

**Гамил Афзал**: мәкаләләр, истәлекләр, шигырьләр, хатлар, әңгәмәләр /[төз.: Н. Афзалова, Л. Шәех]. – Казан: Рухият, 2016. – 327 б.: фоторәс. б-н.

**Галиуллин Т.** Шәхесне гасырлар тудыра: әдәби тәнкыйть, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 192 б. – Тынгысыз каләмнең үлемсез шигърияте. – Б. 83–90.

**Афзалова Н.** Күңел түрендәге якты хатирәләр; **Шәех Л**. Күңелдә моң-сагыш тирбәлә; **Шәфигуллин Ф.** Намус тавышы; **Яхин А.** «Иҗаты намуслыгы, тыйнаклыгы белән матур...»; **Галиуллин Т.** Тынгысыз каләмнең үлемсез шигърияте; **Аның турында** каләмдәшләре; **Библиография**: [Г.Афзалның

басылып чыккан китаплары] //Мәйдан. Чаллы. – 2017. – № 5. – Б. 66–75; 76–79; 96–100; 104–106;107–111; 112–113; 114–117.

**Лерон Л.** Гомерлек иман // Безнең мирас. – 2016. – № 6. – Б. 68–71.

**Бәйрәмова Ф.** «Татар икәнемне онытмадым...» //Мәдәни җомга. – 2016. – 22 июль. – Б. 17; 29 июль. – Б. 17.

**Мирза М.** Гомерләр кичкәндә // Казан утлары. – 2016. – № 5. – Б. 110–118.

**Хәким С.** Мин чәчәкләр җыям; **Нажар Н.** Шагыйрь дөньясы; **Шәфигуллин Ф.** Намус тавышы; **Юныс М.** Үзе китте, җыры калды; **Садриев Ф.** Йөрәге халык күкрәгендә // Мәдәни җомга. – 2016. – 27 май. – Б. 6, 8–9, 12.

**Шәрифуллина Э.** Алтын тапсам, сезгә бирермен //Ватаным Татарстан. – 2019. – 23 гыйн. – Б. 3.

**Гиниятуллина А.** Писатели Советского Татарстана: биобиблиогр. справочник. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 511 с. – Гамил Афзал. – С. 38–39.

**Мингараев И.** Народный поэт Татарстана // Нефть и жизнь. – 2011. – № 4. – С. 36–37.

**Дашина А.** Тонкий лирик с душой // Респ. Татарстан. – 2011. – 30 сент. – С. 3.

**3** июль/июля



**Пётр Евгеньевич Корнилов**
1896—1981

тууына 125 ел
125 лет со дня рождения

Сәнгать белгече, музей эшлеклесе, коллекционер, библиофил Пётр Евгеньевич Корнилов 1896 елның 3 июлендә Сембер (хәзер Ульяновск) шәһәрендә туа. 1915 елда Казанда Беренче реаль училищены тәмамлагач, 1915–1917 елларда Мәскәү җир төзү институтында укый, шуннан Кызыл Армия сафларына чакырыла.

Демобилизациядән соң, 1921–1930 елларда (бүленеп, 1922–1925 елларда Ленинград университетында укый) ТАССР Үзәк музеенда сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре, китапханәче, гыйльми секретарь һәм бер үк вакытта ТАССР Халык мәгариф комиссариатының музей бүлегендә гыйльми секретарь була.

1927, 1928, 1930 елларда шәрык (көнчыгыш) архитектурасы һәм сәнгате ядкәрләрен өйрәнү өчен Урта Азиягә бара. 1930–1932 елларда Бохарада музей төзелеше белән шөгыльләнә. 1932 елдан Ленинградта яши.

1920 нче елларда П.Е.Корниловның күпьяклы эшчәнлеге нәтиҗәсендә Татарстанның сәнгать белеменә һәм музей эшенә ныклы нигез салына. ТАССР Үзәк музееның фәнни хезмәткәре буларак, ул музей тарихында беренче тапкыр борынгы рус сәнгате бүлеген оештыра. Моның өчен хакимият тарафыннан Казан чиркәүләре һәм соборлары ябылган вакытта музейга тапшырылган күпсанлы сәнгать әсәрләрен




(иконалар, чигелгән әйберләр, вак пластика һ.б.) барлап-ачыклап чыга. Казанда Мәскәү һәм Ленинградның күренекле рәссамнары әсәрләреннән күргәзмәләр оештыра; әлеге күргәзмәләргә каталоглар төзи; бу эшләрдә катнашу өчен шушы шәһәрләрдән әйдәп баручы сәнгать белгечләрен чакыра.

Ул даими рәвештә китап ядкәрләренә багышланган докладлар белән чыгышлар ясый; Казанда басылган сәнгать әсәрләрен тикшерә; Казан рәссамары арасында экслибриска карата кызыксыну уята, экслибрис күргәзмәләрен оештыра һәм аларның җыентыкларын бастыра.

П.Е.Корнилов Казан график-рәссамнарын туплаган «Всадник» берләшмәсенең беренче историографы була, аның әйдәп баручы осталарының – Н.И.Шикалов, М.А.Андриевская, И.Н. Плещинский, К.К.Чеботаревның күргәзмәләрен оештыра; халык арасында аз билгеле һәм онытылган рәссамнарның иҗатлары турында очерклар яза.

Ул – мәдәният һәйкәлләрен саклау һәм өйрәнү эшен оештыручы да. Казан һәм Тәтеш шәһәрләрендәге иконография сәнгатен, болгар һәйкәлләре торышын, беренче булып Казандагы зиратларның архитектура-сәнгати халәтен һ.б. тикшерә. Казан архитектура-сәнгать остаханәләрендәге, Тәтеш музейларындагы коллекцияләрнең торышын тасвирлый.




*Шиллинговский П.А. П.Е.Корниловның экслибрисы, 1924 ел*

1927 елда И.И.Шишкинның 100 еллык юбилеен үткәрү буен-

ча оештыру комитетын җитәкли; ул рәссам мирасын өйрәнү һәм Алабуга шәһәрендә мемориаль музей булдыру максатын куя.

1920 нче елларда П.Е.Корниловның төбәк сәнгати мирасы белән фәнни кызыксынуны гомумроссия кысаларында активлаштыруы заманча сәнгать һәм нәшрият эше үсешенә зур ярдәм итә.

Пётр Евгеньевич Корнилов сәнгать фәннәре кандидаты, профессор. Ул 1981 елның 10 октябрендә Ленинград шәһәрендә вафат була.



*Пётр Корнилов. Иркутск, 1920 год*

Искусствовед, музейный работник, библиофил, коллекционер Пётр Евгеньевич Корнилов родился 3 июля 1896 года в городе Симбирске (ныне Ульяновск). После окончания в 1915 году Первое Казанское реальное училище в 1915–1917 годах учится в Московском межевом институте, оттуда призывается в Красную Армию.

После демобилизации, в 1921–1930 годах работает (с перерывом на время учёбы в 1922–1925 годах в Ленинградском университете) в Центральном музее ТАССР научным сотрудником художественного отдела, библиотекарем, учёным секретарем, одновременно – учёным секретарем в Музейном отделе Наркомата просвещения ТАССР.

В 1927, 1928, 1930 годах совершает поездки в Среднюю Азию для изучения памятников архитектуры и искусства Востока. В 1930–1932 годах работает над созданием музея в городе Бухаре. С 1932 года живёт в Ленинграде.

В 1920-е годы в результате многогранной деятельности П.Е.Корнилова была заложена прочная основа искусствознания и музейного дела Татарстана. Будучи научным сотрудником Центрального музея ТАССР, ученый создаёт первый



*Шиллинговский П.А. Портрет П.Е.Корнилова, 1925 год*

за всю историю музея отдел древнерусского искусства, для чего проводит первичную атрибуцию большого количества произведений (икон, лицевого шитья, мелкой пластики), изъятых властями из казанских церквей и соборов. Организует в Казани выставки произведений известных художников из Москвы и Ленинграда, составляет каталоги данных выставок, привлекая к участию в них ведущих искусствоведов этих столичных городов.

П.Е.Корнилов регулярно выступает с докладами, посвящёнными казанским книжным раритетам; исследует художественные издания Казани; активно формирует интерес к экслибрису в среде казанских художников, организует выставки экслибристов и издаёт их сборники.

П.Корнилов – первый историограф объединения казанских художников-графиков «Всадник», организатор выставок его ведущих мастеров: Н.И.Шикалова, М.А.Андриевской, И.Н.Плещинского, К.К.Чеботарева; автор очерков о малоизвестных и забытых художниках.

Ученый вносит большой вклад в организацию охраны и изучения памятников культуры, исследует художественную иконографию Казани и города Тетюши, состояние болгарских памятников, первым обращается к изучению архитектурно-художественного облика казанского некрополя, описывает художественные коллекции музея казанских архитектурно-художественных мастерских, Тетюшского музея.

В 1927 году исследователь возглавляет оргкомитет по проведению 100-летнего юбилея И.И.Шишкина, инициирует изучение наследия художника и создание мемориального музея в городе Елабуга.

В 1920-е годы область научных интересов П.Е.Корнилова была сосредоточена вокруг художественного наследия края в общероссийском контексте, современного искусства и издательского дела.

Кандидат искусствоведения, профессор Пётр Евгеньевич Корнилов скончался 10 октября 1981 года в городе Ленинграде.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Корнилов П.Е.** А.Н.Рокович: 1815–1866 гг.: материалы к словарю казанских художников. – Казань, 1926. – 131–146 с.: ил. – Библиогр.: с.10. – Прим.: с. 142–143.

**Корнилов П.** Отделение древне-русского искусства /Центральный музей ТССР. – Казань, 1927. – 4 с.: ил. – Отд. отт. из изд. «Материалы Центр. Музея ТССР», Вып. 1, 1927 г.

**Корнилов П.Е.** Памятник Волжского судоходства галера «Тверь» XVIII в. / Отд. по делам музеев и охраны памятников ТАССР. – Казань, 1927. – 31 с.: ил.

**Корнилов П.** Старинный вид Казани. – Казань: 1-я гостипография «Красный печатник», 1927. – 7 с.: ил. – Примеч.: с. 7. – Отд. отт. Из «Вестник Науч. о-ва татароведения». – 1927. – № 6.

**Корнилов П.Е.** Охрана памятников ТССР: 1917–1927 гг. / Отд. по делам музеев и охраны памятников искусства, старины и природы при Акад. Центре ТНКП. – Казань, 1928. – 14 с.: ил. – Отд. отт. из журн. «Вестник Науч. О-ва Татароведения». – 1928. – № 8.

**Корнилов П. Е.** К изучению эпиграфического резного камня болгаро-татарской эпохи / Музейный отдел ТССР. – Казань, 1929. – 10 с. – Примеч.: с. 8–9.

**Корнилов П.** На родине И.И.Шишкина. – Казань, 1929. – 8 с.: ил. – Прим.: с. 8.

**Корнилов П. Е.** Художественные издания Казани за 10 лет (1917–1927 гг.) – Казань: Татполиграф, 1930. – С. 79–84. – Отд. отт. из журн «Труды общества изучения Татарстана».

**Корнилов П. Е.** Художник-гравер Иван Николаевич Павлов. – Казань, [1930]. – 6 с.: ил., автопортр.

**Актуальные вопросы** развития искусствоведения в России, странах СНГ и тюркского мира: материалы Междунар. науч. конф., посвящ. 120-летию со дня рождения Петра Евгеньевича Корнилова (1896–1981), Казань, 18–19 мая 2017 г. Ч. I. Жизнь и творчество П.Е.Корнилова. – Казань, 2017. – 168 с. – Труды П.Е.Корнилова. – С. 150–164.

**Ключевская Е.П.** «Знать прошлое, дабы строить настоящее...» // Татарстан. – 1996. – № 12. – С. 51–55.

**Ключевская Е.П.** Пётр Евгеньевич Корнилов – знаток и коллекционер экслибриса // Краеведческие среды: материалы заседаний, прошедших в Национальном музее РТ в 2003 году. – Вып. 4. /Национальный музей РТ. – Казань: Школа, 2004. – С. 107–118.

**Каргалова Т.А.** П.Е.Корнилов как заведующий библиотекой Центрального музея Татреспублики // Дьяконовские чтения: материалы 2001 г. / Национальный музей РТ. – Казань, 2001. – С. 52–57.

**10** июль/июля



**Фатих Колбарисов**
**Фатых Кульбарисов**
1921—1981

тууына 100 ел
100 лет со дня рождения

Драма актёры Фатих Әкрам улы Колбарисов 1921 елның 10 июлендә Башкортстан АССРның Мишкә кантоны Субай авылында туа. 1930 нчы елларда алар гаиләләре белән Казанга күчеп киләләр.

Ф.Колбарисов сәхнә эшчәнлеген 1937 елда Татар академия театрында ярдәмче состав актёры сыйфатында башлап җибәрә. 1941 елда шул ук театр каршындагы студияне тәмамлый һәм төп составта эшли башлый.

Нарский («Серләр», А.Әхмәт), Бикбулат, Вәзир («Рәйхан», «Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), доктор Ломбарди («Ике хуҗаның хезмәтчесе», К.Гольдони), Миллер («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер) кебек шактый үзенчәлекле образлар тудыра.

Батырхан образы («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин) Ф.Колбарисов иҗатына зур үзгәреш алып килә: әлеге геройны гәүдәләндергәндә актёр эчтәлек һәм форма берлегенә ирешә; тарих тәгәрмәчен кирегә борырга тырышучы образы аның тарафыннан гротеск дәрәҗәсенә җиткерелә. Бу роле өчен ул 1958 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Хөрмәтулла («Җиз кыңгырау», А.Гыйләҗев), Яков Бардин («Дошманнар», М.Горький), Мартин («Сукыр», Э.Альт), Максим («Ата хакы – Тәңре хакы», В.Лаврентьев), Паскуалино



*К.Тинчурин «Җилкәнсезләр». Батырхан ролендә Ф.Колбарисов (сулда)*

(«Бәйрәм кичендә», Эд. де Филиппо), Лавр Мироныч («Соңгы корбан», А.Островский), Дятлов («Баһадирлар», Н.Ф.Погодин), Розенберг, Әҗәл («Моңлы бер җыр», «Әлдермештән Әлмәндәр», Т.Миңнуллин) образларын да Ф.Колбарисов югары дәрәҗәдә, төгәл итеп яктырта.

Нәфис сүз остасы буларак, Ф.Колбарисов еш кына радиотапшыруларда һәм концертларда катнаша: татар шагыйрьләренең шигъри әсәрләрен укый; 1944–1948 елларда Татарстан радиосы дикторы булып эшли.

Ф.Колбарисов «Юлдан язган» («Блудный сын», Э.Раннет), «Кол» («Эзоп», Г.Фигейредо), «Ешрак елмаегыз!» («Сослуживцы», Э.В.Брагинский, Э.А.Рязанов) һ.б. шактый гына пьесаларны татарчага тәрҗемә итә.

1968 елда Ф.Ә.Колбарисовка ТАССРның атказанган артисты дигән мактаулы исем бирелә.

Ф.Ә. Колбарисов 1981 елның 7 октябрендә Казанда вафат була.




Драматический актёр Фатых Акрамович Кульбарисов родился 10 июля 1921 года в деревне Субаево Мишкинского кантона Башкирской АССР. В 1930-е годы семья переезжает в Казань.

Сценическую деятельность Ф. Кульбарисов начинает в 1937 году в вспомогательном составе Татарского академического театра. В 1941 году заканчивает студию при этом театре и переходит в основной состав труппы.

Театральные роли Ф. Кульбарисова отмечены своеобразием решения: Нарский («Тайны» А.Ахмета), Бикбулат, Визирь («Райхан», «Ходжа Насретдин» Н.Исанбета), доктор Ломбарди («Слуга двух господ» К.Гольдони), Миллер («Коварная любовь» Ф.Шиллера).

Переломным в творчестве Ф.Кульбарисова становится образ Батырхана («Без ветрил» К.Тинчурина): актёр талантливо сочетает содержание и форму; образ буржуазного националиста, пытающего повернуть колесо истории вспять, был решён им в жанре гротеска. За эту роль в 1958 году актер удостоен Государственной премии Татарстана им. Г.Тукая.

Глубоким проникновением в сущность образа были отмечены последующие работы актёра, среди которых: Хурматулла («Медный колокол» А.Гилязова), Яков Бардин («Враги» М.Горького), Мартин («Слепой» Э.Альта), Максим («Чти отца своего» В.Лаврентьева), Паскуалино («Рождество в доме сеньора Купьелло» Эд. де Филиппо), Лавр Мироныч («Последняя жертва» А.Островского), Дятлов («Третья, патетическая» Н.Ф.Погодина), Розенберг, Азраил («У совести вариантов нет», «Альмандар из Альдермыша» Т.Миңнуллина).

Мастер художественного слова, Ф.Кульбарисов неоднократно принимает участие в радиопередачах и концертах с произведениями татарских поэтов; в 1944–1948 годах работает диктором татарского радио.

Ф.Кульбарисов переводит на татарский язык ряд пьес, среди которых «Блудный сын» Э.Раннета, «Эзоп» Г.Фигейредо, «Сослуживцы» Э.В.Брагинского, Э.А.Рязанова.

В 1968 году Ф.А.Кульбарисову присуждается почётное звание заслуженного артиста ТАССР.

Ф.А.Кульбарисов скончался 7 октября 1981 года в Казани.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Г.Камал исемендәге** Татар дәүләт академия театры. 2 томда. Т. 2. – Казан: Заман: Татар. кит. нәшр., 2009. – 368 б.: ил. – Колбарисов Фатих Әкрам улы. – Б. 92–93. – Текст парал. на рус.

**Арсланов М.Г.** Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. – Казан: Заман, 2014. – 584 б. – Колбарисов Фатих Әкрам улы. – Б. 328.

**Шакиров Ә.** Артист ул фәрештә түгел // Шәһри Казан. – 2006. – 3 февр.

**Шакирҗан Л.** Хыялдагы Дон Кихот // Шәһри Казан. – 2001. – 13 июль.

**Гыйззәт Б.** Вәгъдәгә тугрылык // Соц. Татарстан. – 1981. – 12 июль.

Кумысников Х. Тыйнак кеше, сәләтле кеше // Казан утлары. – 1972. – № 5. – Б. 164–168.

**Гимранова Д.** Ответственность – качество обязательное // Веч. Казань. – 1981. – 6 авг.

**Кумысников Х.** Со сцены – только правду // Сов. Татария. – 1981. – 12 июля.

**Кумысников Х.** Актёр современности: творческий портрет Кульбарисова // Сов. Татария. – 1965. – 17 дек.

**15** июль/июля



**Асия Хәйруллина**
**Асия Хайруллина**
1921—2004

тууына 100 ел
100 лет со дня рождения

Драма артисты, педагог Асия Хәсән кызы Хәйруллина 1921 елның 15 июлендә Казан губернасы Свияжск (Зөя) кантоны (хәзер Татарстан Республикасының Югары Ослан районы) Кызыл Байрак авылында туа.

1949 елда Асия Хәйруллина Мәскәүдә Театр сәнгате дәүләт институтының (ГИТИС) татар студиясен тәмамлый һәм Казан яшьләр театрының татар төркеменә кабул ителә. Бер елдан Татар академия театрына эшкә чакырыла. Башта травести амплуасындагы артистка – тапкыр, бөтен җиргә өлгерә торган малайлар һәм кызлар булып уйный: Садрый, Малай («Галиябану», «Ак калфак», М.Фәйзи), Миңлеәхмәт («Миңлекамал», М.Әмир), Идел («Зифа», Н.Исәнбәт), Зөлкагыйдә («Кыю кызлар», Т.Гыйззәт).

Соңрак ул төрле характердагы образлар иҗат итә – Нурсәнә, Гүзәл («Беренче мәхәббәт», «Рәхим итегез», Х.Вахит), Екатерина («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш) һ.б. Кәрим Тинчуринның «Җилкәнсезләр» пьесасы буенча куелган спектакльдә Рокыя роле актрисаның зур уңышы була. Бу рольне башкарганы өчен Асия Хәйруллина 1958 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

1962 елда А.Хәйруллина педагоглык эшенә күчә: Казан театр училищесында сәхнә телен укыта; бер үк вакытта, 1970–


*К.Тинчурин «Җилкәнсезләр».*
*А.Хәйруллина, Г. Шамуков*

1976 елларда Казан дәүләт мәдәният институтында да дәресләр алып бара. Ул – сәхнә теленнән методик кулланмалар (ярдәмлекләр) авторы да.

1992 елда Асия Хәйруллинага Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә.

Асия Хәсән кызы Хәйруллина 2004 елның 4 ноябрендә вафат була.

Драматическая актриса, педагог Асия Хасановна Хайруллина родилась 15 июля 1921 года в посёлке Кзыл Байрак Свияжского кантона Казанской губернии (ныне Верхнеуслонский район Республики Татарстан).

В 1949 году после окончания татарской студии Государственного института театрального искусства (ГИТИС) в Москве, поступает в татарскую группу Казанского ТЮЗа, через год переводится в труппу Татарского академического театра. Как актриса-травести играет роли Садри, Мальчика («Галиябану», «Белый калфак» М.Файзи), Минниахмата («Миннికамал» М.Амира), Иделя («Зифа» Н.Исанбета), Зулькагиды («Смелые девушки» Т.Гиззата) – смекалистых, всюду поспевающих деревенских мальчишек и девчонок.

Позднее актриса переходит на характерные роли – Нурсана, Гузель («Первая любовь», «Добро пожаловать» Х.Вахита), Екатерина («Молодые сердца» Ф.Бурнаша) и др. Значительным достижением актрисы становится роль Рокии в спектакле «Җилкәнсезләр» («Без вертил») по пьесе К.Тинчурина. За исполнение этой роли А.Хайруллина в 1958 году была удостоена Государственной премии Татарстана им. Г.Тукая.

В 1962 году А.Хайруллина переходит на педагогическую работу: преподает сценическую речь в Казанском театральном училище, в 1970–1976 годах – в Казанском государственном институте культуры; является автором методических пособий по сценической речи.

В 1992 году А.Х.Хайруллиной присвоено почётное звание заслуженного деятеля искусств Республики Татарстан.

А.Х.Хайруллина умерла 4 ноября 2004 года.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***


**Хәйруллина А.Х.** Тел күрке – сүз (матур сөйләргә өйрән). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 112 б.

**Хәйруллина А.Х.** Дөрес сөйләргә өйрәнегез. – Казан, 1992. – 96 б.

**Хәйруллина А.** Ничек тиз узасың син, гомер...: [очерклар, хатирә-истәлекләр, әңгәмәләр] /төз. һәм кереш сүз авт. Г.С.Нуриев. – Казан: Заман, 2012. – 255 б.: рәс.

**Г.Камал исемендәге** Татар дәүләт академия театры. 2 томда. Т. 2. – Казан: Заман: Татар. кит. нәшр., 2009. – 368 б.: ил. – Хәйруллина Асия Хәсән кызы. – Б. 147–148. – Текст парал. на рус.

**Арсланов М.Г.** Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. – Казан: Заман, 2014. – 584 б. – Хәйруллина Асия Хәсән кызы. – Б. 536.

**Имашев М.** Остаз-мөгаллимә иде ул // Сәхнә. – 2009. – № 6. – Б. 10–11.

**Кумысников Х.** Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Асия // Сөембикә. – 2001. – № 1. – Б. 28–29.

**Миңлебаев К.** Кыйблага тугрылык // Татарстан. – 1992. – № 2. – Б. 73–78.

**Солтанов Һ.** Һаман шулай булып калыгыз ! // Шәһри Казан. – 1992. – 17 гыйн.

**Хәбибуллина Л.** Тормышка ашкан хыял // Шәһри Казан. – 2001. – 20 июль.

**Кумысников Х.** Правда добра и любви: Чистое слово Асии Хайруллиной // Казань. – 1997. – № 1–2. – С. 39–41.

**16** август/августа



**Рөстәм Яхин**
**Рустем Яхин**
1921—1993

тууына 100 ел
100 лет со дня рождения

Композитор Рөстәм Мөхәммәтхаҗи улы Яхин 1921 елның 16 августында Казан шәһәрендә туа. 13 яшьтә Казанның 1-нче санлы балалар музыка мәктәбенә укырга керә. Белем алуын Мәскәүдә дәвам итә. 1941 елда, Мәскәү музыка училищесын тәмамлагач, Мәскәү консерваториясенә укырга керә. Ләкин Бөек Ватан сугышы башлана. Р.Яхин башта зенит-артиллерия дивизиясендә укчы, аннары Мәскәү фронтының җыр һәм бию ансамблендә пианист-аккомпаниатор булып хезмәт итә.

Сугыштан соң Р.Яхин Мәскәү консерваториясендә укуын дәвам итә: композиция классында – профессорлар В.А.Белый, аннары Ю. А. Шапоринда һәм фортенианога махсус В.М.Эпштейн классында. Мәскәүдә укыган еллары композиторның һөнәри осталыгын һәм иҗади фикерләвен формалаштыруга зур йогынты ясый. Диплом эше сыйфатында Р.Яхин «Фортепиано белән



*Рөстәм Яхин әнисе белән. 1970 еллар*

оркестр өчен концерт» тәкъдим итә (Беренче өлеш), ул киң резонанс тудыра (1950).


Рөстәм Яхин. 1970 еллар ахыры

1950 елда яшь композитор Казанга кайта һәм үзенең фортепиано өчен концерты өстендә эшләвен дәвам итә, 1951 елда аның ике бүлеген тәмамлый. Бу татар музыкасында фортепиано белән оркестр өчен беренче концерт була һәм ул хәзерге көнгә кадәр республикада әлеге жанрның иң танылган һәм күп башкарыла торган әсәре булып кала.

1950–1952 елларда Р.Яхин Казан консерваториясендә композиция укыта. Шуннан соңгы елларда ул музыка иҗат итү һәм концерт эшчәнлеге белән актив шөгыльләнә.

Иҗатының башында ул зур формадагы берничә инструменталь әсәр – «Скрипка һәм фортепиано өчен соната», «Скрипка һәм фортепиано өчен поэма», «Фортепиано өчен соната», «Фортепиано концерты» иҗат итә.

Алга таба Р.Яхин инструменталь музыка өлкәсендә, миниатюра жанрында эшли, Европаның төрле милли композиторлык мәктәпләре традицияләрендә үзенең иҗатын камилләштерә. Ул төрле характердагы пьесалар иҗат итә, кайвакыт аларны циклларга берләштерә. Аның вальс, ноктюрн, музыкаль момент, юмореска һ. б. жанрларда искиткеч, аңа гына хас индивидуаль әсәрләре бар.

Р. Яхин – камера-вокал һәм камера-инструменталь музыканың иң танылган осталарыннан берсе. Аның иҗатында фортепиано өчен язылган әсәрләр аерым урын алып тора. Ул татар фортепиано сәнгатенә нигез салучы буларак та, композитор буларак та, беренче татар концертчысы буларак та зур уңыш казана. Р.Яхинның фортепиано әсәрләре – татар пианистлары репертуарының алтын фонды. Пианист буларак ул үзенең әсәрләрен генә түгел, ә рус һәм чит ил фортепиано классикасы әсәрләрен дә башкара.




Композитор заманча татар җыр мәдәниятен үстерүгә дә үзеннән зур өлеш кертә. Аның «Туган ягым» җырының музыкасы 1993 елда Татарстан Республикасының Дәүләт Гимны итеп раслана.

Р.Яхинга ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1964), РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1977), РСФСРның халык артисты (1981), СССРның халык артисты (1986) дигән мактаулы исемнәр бирелә. Ул – Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

Р. Яхин 1993 елның 23 ноябрендә вафат була. Казанның Яңа Татар бистәсендәге татар зиратында җирләнә.

2003 елдан башлап Казанда камера җырчыларының һәм концертмейстерларның Р.Яхин исемендәге Халыкара конкурсы үткәрелә. Казанда Р.Яхин яшәгән йортка мемориаль такта урнаштырыла; шәһәрнең бер урамы аның исеме белән атала; Казан консерваториясе каршында композиторга һәйкәл (скульпторлар А. Миңнуллина һәм А. Балашов; архитектор Г. Бакулин) куела.

Композитор Рустем Мухаметхазеевич Яхин родился 16 августа 1921 года в Казани. В 13 лет поступает в детскую музыкальную школу № 1 города Казани. Обучение продолжает в Москве. В 1941 году после окончания Московского музыкального училища поступает в Московскую консерваторию. С началом Великой Отечественной войны Р.Яхин служит стрелком в зенитно-артиллерийской дивизии, затем – пианистом-аккомпаниатором в ансамбле песни и пляски Московского фронта ПВО (1942–1945 гг.).






После войны Р.Яхин продолжает учёбу в Московской консерватории по классу композиции у профессоров В.А.Белого и Ю.А.Шапорина, по классу специального фортепиано – у В.М.Эпштейна. Годы учебы в Москве оказывают большое влияние на формирование профессионального мастерства и творческого кругозора композитора. В качестве дипломной работы Р.Яхин представляет «Концерт для фортепиано с оркестром» (первую часть), который вызывает широкий общественный резонанс (1950).

В 1950 году молодой композитор возвращается в Казань, продолжает работу над своим фортепианным концертом, завершив в 1951 году ещё две его части. Это был первый в татарской музыке концерт для фортепиано с оркестром, который до настоящего времени остаётся в республике самым известным и исполняемым произведением этого жанра.

В 1950–1952 годах Р.Яхин преподает композицию в Казанской консерватории. В последующие годы он активно занимается сочинением музыки и концертной деятельностью.

В начале творческого пути им было создано несколько инструментальных произведений крупной формы: «Соната для скрипки и фортепиано», «Поэма для скрипки и фортепиано», «Соната для фортепиано», «Фортепианный концерт».




В дальнейшем Р.Яхин работает в области инструментальной музыки, в жанре миниатюры, творчески развивает традиции разных европейских национальных композиторских школ. Композитор создаёт ряд разнохарактерных пьес, некоторые из которых




были объединены в циклы. Автору принадлежат замечательные, яркие сочинения в таких жанрах, как вальс, ноктюрн, музыкальный момент, юмореска и др.

Р.Яхин является одним из самых выдающихся мастеров камерно-вокальной и камерно-инструментальной музыки. Особое место в творчестве композитора занимают сочинения для фортепиано. Он оказал большое влияние на развитие татарского фортепианного искусства, фактически выступив его основателем как композитор и как первый татарский концертирующий пианист. Фортепианные сочинения Р.Яхина – это золотой фонд репертуара татарских пианистов. Как пианист он исполняет не только собственные сочинения, но и произведения русской и зарубежной фортепианной классики.

Композитор внёс большой вклад в развитие современной татарской песенной культуры. Его музыка к песне «Туган ягым» («Родной край») в 1993 году была утверждена Государственным Гимном РТ.

Р.Яхину присвоены почётные звания: заслуженного деятеля искусств ТАССР (1964) и РСФСР (1977), народного артиста РСФСР (1981) и СССР (1986), лауреат Государственной премии Татарстана им. Г.Тукая.

Р.Яхин умер 23 ноября 1993 года. Похоронен на татарском кладбище в Ново-Татарской слободе Казани.

С 2003 года в Казани проводится Международный конкурс камерных певцов и концертмейстеров им. Р.Яхина. В Казани на доме, в котором жил Р.Яхин, установлена мемориальная доска; его именем названа улица; у здания Казанской консерватории открыт памятник композитору (скульпторы А.Минуллина и А.Балашов; архитектор Г. Бакулин).

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Яхин Р.** Дулкыннар: җырлар һәм романслар: фортепианога кушылып җырлау өчен. – Казан: Татар. Кит. нәшр., 1964. – 55 б.: ноталар б-н..

**Яхин Р.** Ак җилкән: җырлар һәм романслар / кереш сүз авт. Й. Исәнбәт]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 120 б.: ноталар б-н.

Яхин Р. Йолдызлы кичләр: җырлар һәм романслар. – Казан: Матбугат йорты, 2002. – 112 б.: портрет белән.

**Яхин Р.** Песни и романсы [ноты] = Songs and romances: для голоса в сопровождении фортепиано; [авт. предисл. С.Гурарий]. – М.: Сов. композитор, 1987. – 152 с.: фото.

**Яхин Р.М.** В душе весна [ноты]: песни и романсы (для голоса в сопровождении фортепиано): [ в 2–х частях]. – Казань: Идел–Пресс, 2010. – Ч. 1. – 2010. – 74 с. – В предисл. инф. об авт. на рус., татар. яз. и англ. яз.

**Яхин Р. М.** Пьесы для фортепиано = Фортепиано өчен пьесалар: [Ноты] /сост. З. А. Ибрагимова. – Казань: Наследие булгар, 2013. – Текст парал. на рус. и татар. яз.

Ч.1. – 2013. – 73 с.

Ч.2. – 2013. – 85 с.

**Рөстәм Яхин:** үзем турында: [композиторның үз кулы белән язылган тәрҗемәи хәле] / русчадан Р.Низами тәрҗ. // Идел. – 2005. – № 6. – Б. 42–44.

**Нигъмәтҗанов М.** Халык күңеленең аһәң сазы: // Мәдәни җомга. – 2011. – 16 сентябрь. – Б. 11.

**Монасыйпов Ш.** Назлы моң // Казан утлары. – 2001. – № 10. – Б. 135–144.

**Любовский Л.** Бармы олы җанга тынычлык; Фәйзи З. Күңелдә дә, истә дә // Казан. – 1996. – № 7–8. – Б. 42–44; 48–51.

**Хөсәенов Ш.** Газап диңгезен эчеп... // Казан утлары. – 1996. – № 8. – Б.148–160.

**Айрат Арсланов:** истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 239 б. – Зәңгәр томаннар артында калган мизгелләр. – Б. 197–201.

**Арслан А.** Күңелендә һәрчак яз иде // Мәдәни җомга. – 2001. – 17 авг. – Б. 12.

**Хисамов Н.Ш.** Хәтер сагында: әдәби-фәнни мәкаләләре, иҗат портретлары һәм публицистика. – Казан: Мәгариф, 2004. – 620 б. – Илаһи моң: (Рөстәм Яхинга бәйләнешле истәлекләр). – Б. 461–466.

**Ильясов Р.** Олы сәнгатькә багышланган гомер // Шәһри Казан. – 2012. – 31 гыйнвар. – Б. 11.

**Бәдигый Х.** Мәңгелекнең бер төре // Мәдәни җомга. – 2011. – 16 дек. – Б. 11.

**Газизова Л.** Нечкә күңел нигә телгәләнгән? // Шәһри Казан. – 2013. – 26 ноябрь. – Б. 5.

**Галиев М.** Әсәрләр. 6 томда. Т.5. – Казан: Идел-Пресс, 2011. – 448 б. –Сүзсез дога. – Б. 131– 140; Сәхнә. – 2005. – № 11-12. – Б. 14–16.

**Мортазина А.** Аның гимны белән яшибез // Шәһри Казан. – 2013. – 26 нояб. – Б. 5.

**Низами Рашат.** Яшәүгә гимн. – Казан: Идел-Пресс, 2011. – 32 б.

**Вәлиева Г.** Яшәү гимны: [әдәби-музыкаль кичә] // Мәгариф=Просвещение. – 2011. – № 8. – Б. 59–61.

**Рустем Яхин** в воспоминаниях современников / М-во культуры РФ; Казан. гос. консерватория им. Н.Г.Жиганова; [сост.-ред., авт. предисл. Ф.И.Хасанова]. – 2-е изд., доп. – Казань: Казан. гос. консерватория, 2004. – 294 с.

**Рустем Яхин** в воспоминаниях современников / Казан. гос. консерватория; АН Татарстана; Союз композиторов Респ.Татарстан; сост. Ф.И.Хасанова. – Казань, 1996. – 275 с.: 16 л.: ил.

**Рустем Яхин:** Материалы. Письма. Воспоминания / общ. ред., вступ. ст., коммент. и указ. Ю.Н.Исанбет; сост.: Ю.И.Исанбет, К.С.Тазиева, А.М.Мусина. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. – 431 с., 24 л. фотоил.: ил. – На рус. и татар. яз.

**Рустем Яхин:** Стиль творчества: сб. науч. ст. / М-во культуры РФ; Казан. гос. консерватория им. Н.Г.Жиганова; сост. и науч. ред. В.Р.Дулат-Алеев. – Казань: Казан. гос. консерватория, 2002. – 152 с.

**Рустем Яхин:** биобиблиогр. указ., 1935–1996 / авт.-сост. Ю.Исанбет. – Казань: Магариф, 2001. – 120 с.

**Нигмедзянов М.Н.** Народ достоин подлинного искусства. – Казань, 2017. – 415 с.: ил. – Рустем Яхин. – С. 130–133.

**Монасыпов Ш.** Звезда любви: штрихи к духовному портрету Рустема Яхина // Казань. – 1999. – № 11. – С. 42–47.

**Шарифуллина Н.** Прививка от ностальгии // Казань. – 2011. – № 8. – С. 52–55.

**Хайрутдинов А.** Забыть не в силах; **Сунгатуллина З.** Гений общения; **Хасанова Ф.** Власть волшебной музыки; **Шагимуратова А.** Божественный дар; **Абдуллин Р.** Благородная душа // Казань. – 2011. – № 10. – С. 60–63; 64–65; 65–67; 67–68; 69.

**20** август/августа



**Гази Заһитов**
**Гази Загитов**
1921—1953

туына 100 ел
100 лет со дня рождения

Бөек Ватан сугышы каһарманы Гази Казыйхан улы Заһитов 1921 елның 20 августында Башкортстан АССРның Мишкә районындагы татар авылы Яңагышта (Яңакош) туа. Башлангыч белемне туган авылында алгач, Урьяды авылында җидеellык мәктәпне тәмамлый. 1938 елда Бөре медицина техникумына укырга керә.

1940 елның августыннан Г.Заһитов – хәрби хезмәттә. Таллин шәһәрендә кече командирлар курсын тәмамлый. 1941 елның 22 июненнән Бөек Ватан сугышында.




136 нчы армиянең Кызыл Байраклы пушка-артиллерия бригадасына караган разведка дивизионындагы оптик разведка взводының пост башлыгы өлкән сержанты Гази Заһитов 1945 елның апрелендә Берлинны алу өчен барган сугышларда зур тәвәккәллек үрнәкләре күрсәтә. Рейхстагны штурмлаучыларның иң алгы сафында була. 29 апрельдә ул һәм аның иптәшләре немецлар урнашкан җиргә үтеп керәләр һәм безнең артиллерия

утын рейхстагка юнәлдерәләр. Авыр яралануга карамастан, Г. Заһитов 30 апрельдә 22 сәгать 30 минутта, М.А.Егоров һәм М.В.Кантариягә кадәр үк, сугышчан дусты сержант М.П.Минин белән бергә, беренче булып, рейхстаг бинасындагы «Җиңү алиһәсе» скульптурасы таҗына үз частенең Кызыл Байрагын беркетеп куя.



*Рейхстаг түбәсенә беренче булып Кызыл Байрак кадаучылардан Александр Лисименко (сулда) һәм Гази Заһитов*

1945 елның 1 маенда рейхстагны штурмлауда күрсәткән батырлыгы, кыюлыгы, тәвәккәллеге өчен Г.Заһитов Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, ләкин соңыннан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Яу кырында күрсәткән батырлыклары өчен аның II һәм III дәрәҗә Дан орденнары, «Батырлык өчен», «Сугышчан казанышлары өчен» медальләре бар.

Г.Заһитов 1946 елның 1 июлендә армиядән туган авылына кайта. Башкортстан АССРның Мишкә районы Яңагыш авыл советы рәисе, Урьяды МТСында механик булып эшли.

Г.К.Заһитов 1953 елның 23 августында автомобиль һәлакәтенә очрап һәлак була.

Рейхстагка Җиңү байрагын иң беренче булып элгәне өчен Гази Заһитовка һәм аның дүрт иптәшенә, СССР халык депутатлары даими съезды Президиумының 1997 елгы 21 май Указы нигезендә, Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

2007 елда Яңагыш авылында Гази Заһитов исемендәге тарихи-туган якны өйрәнү музее ачыла. Уфа һәм Казан шәһәрләрендәге урамнарга аның исеме бирелә.

2020 елның 9 маенда, Җиңүнең 75 еллыгына, Казанның Җиңү паркында Совет солдатына һәйкәл ачылды. Яңа һәйкәл 1945 елда рейхстаг түбәсенә Кызыл Байрак кадаган татар улы Гази Заһитов образын гәүдәләндерә.




Герой Великой Отечественной войны Гази Казыханович Загитов родился 20 августа 1921 года в татарской деревне Янагушево Мишкинского района Башкирской АССР. Получив начальное образование в родной деревне, продолжает обучение в Урьядской семилетней школе. В 1938 году поступает в Бирский медицинский техникум.

В Советской Армии с августа 1940 года. В Таллине заканчивает курсы младших командиров.

Начальник поста взвода оптической разведки разведдивизиона 136-й армейской пушечной артиллерийской Режецкой Краснознаменной бригады старший сержант Г.Загитов особенно отличается в боях за Берлин. 29 апреля он и его товарищи пробираются в расположение немцев и ориентируют огонь нашей артиллерии на рейхстаг. Несмотря на сквозное ранение, 30 апреля в 22 часа 30 минут Г.Загитов и М.Минин первыми, до М.А.Егорова и М.В.Кантария, установили Красное Знамя своей части в короне скульптуры «Богини Победы» на здании рейхстага.

За храбрость, мужество и героизм, проявленные во время штурма рейхстага, Г.Загитов 1 мая 1945 года был представлен к званию Героя Советского Союза, но впоследствии награждён орденом Красного Знамени. За смелость и решительность в боях награждён орденами Славы II и III степени, медалями «За отвагу». «За боевые заслуги».

1 июля 1946 года Г.Загитов возвращается в родную деревню, работает председателем Янагушевского сельсовета, механиком Урьядинской МТС Мишкинского района Башкирской АССР.

Г.К.Загитов погиб в автокатастрофе 23 августа 1953 года.

21 мая 1997 года Указом Постоянного Президиума Съезда народных депутатов СССР Г.К.Загитову и его четырём боевым товарищам было присвоено звание Героя Советского Союза за водружение Знамени Победы первыми над рейхстагом.

В 2007 году в селе Янагушево открылся историко-краеведческий музей имени Гази Загитова. Его именем названы улицы в Уфе и Казани.

К 75-летию Победы, 9 мая 2020 года в Казани в парке Победы открыт памятник Советскому солдату, прообразом которого стал Г.Загитов.




***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Хәлим А.** Татар солдаты: тарихи-документаль роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 326 б.: фоторәс. б-н.

Батырлар китабы = Книга Героев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 395 б. – Заһитов Гази (Газетдин) Казыйхан улы. – Б. 131.

**Рәкыйпов Ш.** Геройлар үлмиләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 288 б.: рәс., портр. – «Мәңге сакларга». – Б. 81–129.

**Шәфыйков Я.** Бер очрашу – бер гомер. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 208 б.: фото б-н. – Сугышлар шулай бетә. – Б. 149–170.

**Халим А.** Татарский воин: историко-документальный роман / [пер. с татар. А.Халима, А.Галимовой]. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2017. – 341 с.: фото.

**Хамидуллин Б.Л.** Гази Загитов, Григорий Булатов – знаменосцы Великой Победы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. – 87 с.: цв. ил. – (История татар в лицах). – Библиогр. в конце кн.

**Ракипов Ш.** По следам героев. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. – 224 с.: ил., 4 отд. л. портр. – Доблесть / пер. с татар. А.Хазрятова. – С. 209–218.

**Шафиков Я.Д.** Семнадцать интервью в конце века: совершенно несекретно. – Казань: Татар. газ.-журн. изд-во, 1999. – 232 с.: ил. – Гази Загитов: Так кончаются войны. – С. 151–174.

**Шафиков Я.** Кто же первым водрузил Знамя Победы над Рейхстагом? // Казанский альманах. – 2015. – № 14. – С. 65–71.

**Шафиков Я.** Правдивая война Гази Загитова // Звезда Поволжья. – 2015. – 16-22 апр.

**Мустафин Р.** Кто же первым водрузил Знамя Победы над Рейхстагом? //Татарстан. – 2005. – № 4. – С. 46–49.

**Гадельшина Г.** Он был первым // Респ. Татарстан. – 2005. – 6 мая.

**Габдрахманов Х.** Правда о первом Знамени Победы над Рейхстагом // Аргамак. – 1998. – № 3. – С. 138–141.

**17** сентябрь/сентября



**Хәлил Әбҗәлилов**
**Халил Абжалилов**
1896 —1963

тууына 125 ел
125 лет со дня рождения

Драма актёры Хәлил Гали улы Әбҗәлилов 1896 елның 17 сентябрендә Оренбург губернасы Шарлык өязе Мостафа авылында туа. Шагыйрь Муса Җәлилнең ике туган абыйсы. 7 яшендә аны мәдрәсәгә бирәләр. 1906 елда алар гаиләсе белән Оренбургка күчеп килә, биредә Хәлил үзенең хезмәт юлын башлый.

1914 елда, Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, ул патша армиясенә хәрби хезмәткә алына. 1916 елда яраланып, госпитальдә ята, шуннан соң өенә кайтарыла. 1916 елда Оренбургта «Ширкәт» татар драма труппасына керә.

Гражданнар сугышы елларында фронт театр бригадаларында эшли. 1920–1922 елларда Хива һәм Бохара татар театрларында, 1923–1924 елларда Әстерхан дәүләт татар театрында иҗат итә.



1924–1928 елларда Бохара дәүләт киностудиясендә (хәзер – «Үзбәкфильм») «Үлем манарасы», «Рәвәт чүл бүреләре», «Мәчет гөмбәзе астында», «Ябык фургон», «Махау авырулылар», «Икенче хатын» һ.б. фильмнарда катнаша.


Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ендә Хуҗа

1928 елда Х.Әбҗәлилов Казанга килә, Татар академия театрында эшли башлый һәм тиздән аның әйдәп баручы актёры була.

Хәлил Әбҗәлилов – татар халкының олы талантка ия булган мәшһүр артисты. Ул иҗат иткән образлар үзләренең гадилекләре, табигыйлекләре, тышкы яктан беркатлылыклары белән аерылып торсалар да, эчке дөньялары тирән кичерешләргә бай, ачык фикерле, зирәк шәхесләр. Аның рольләре: Локман – «Томан арты» (Ш.Камал), Боцман – «Разлом» (Б.Лавренёв), Тихон – «Яшенле яңгыр», Шмага – «Гаепсездән гаеплеләр» (А.Островский), Омелько – «Мартын Боруля» (И.Карпенко-Карый), Гыйльманов – «Миңлекамал» (М.Әмир), Сиражетдин – «Банкрот» (Г.Камал), Яков – «Соңгылар» (М. Горький), Харитонов – «Диңгездәгеләр өчен» (Б.Лавренёв), Полежаев – «Тынгысыз картлык» (Л.Рахманов), Кучумов – «Котырган акчалар» (А.Островский) һ.б.

Х.Әбҗәлиловка 1939 елда Татарстан АССРның атказанган артисты, 1940 елда РСФСРның атказанган артисты, 1944 елда Татарстан АССРның халык артисты, 1950 елда РСФСРның халык артисты дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар»ында Биктимер, Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ендә Хуҗа, В.Шекспирның «Король Лир» спектаклендә Лир кебек рольләре аны бөек артист итә.

Төп рольләрдә Х.Әбҗәлилов катнашкан әлеге спектакльләр 1957 елда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы вакытында күрсәтелә. Аңа татар театрында беренчеләрдән булып СССРның халык артисты исеме бирелә.

Х.Әбҗәлилов башкаруындагы Мисбах хаҗи роле (К.Тинчурин, «Җилкәнсезләр», 1958) иң күренекле казанышларның берсе буларакраслана. Бу роле өчен ул 1958 елда Татарстан-

ның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Х.Әбҗәлилов Казанның һәм республиканың җәмәгать һәм мәдәният тормышында актив катнаша: 1941–1951 елларда театр әһелләре берлегенең Татарстан бүлеге рәисе, ТАССР Югары Советы депутаты (1947–1959) була.

Хәлил Әбҗәлилов 1963 елның 18 мартында Казан шәһәрендә вафат була, Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнә. Казанда актёр яшәгән йортка мемориал такта куелган, шәһәрдәге бер урам аның исемен йөртә.



*Х.Абжалилов в роли Ходжи Насретдина*

Драматический актёр Халил Галеевич Абжалилов родился 17 сентября 1896 года в селе Мустафино Шарлыкского уезда Оренбургской губернии. Двоюродной брат поэта Мусы Джалиля. В возрасте 7 лет его отдают на обучение в медресе. В 1906 году семья переезжает в Оренбург, здесь Халил начинает свою трудовую деятельность.

В 1914 году, с началом Первой мировой войны, его призывают в царскую армию. В 1916 году после тяжёлого ранения попадает в госпиталь, после демобилизуется. В 1916 году вступает в Оренбургскую татарскую театральную труппу «Ширкэт».

В годы гражданской войны состоит в фронтовых театральных бригадах. В 1920–1922 годах служит в татарских театрах Хивы и Бухары, а в 1923–1924 годах – в Астраханском государственном татарском театре.

В 1924–1928 годах снимается в фильмах Бухарской киностудии (ныне «Узбекфильм») «Минарет смерти», «Шакалы Равата», «Из-под сводов мечети», «Крытый фургон», «Прокажённые», «Вторая жена» и др.

С 1928 года Х. Абжалилов работает в Татарском академическом театре и вскоре становится его ведущим актёром.

Х.Абжалилов – талантливый артист широкого творческого диапазона. Кажущаяся простота, естественность поведения персонажей, умение выстраивать внутреннюю логику характера были отличительными чертами актёра. Он исполнил роли: Лукман – «За туманом» Ш.Камала, Боцман – «Разлом» Б.Лавренёва, Тихон – «Гроза», Шмага – «Без вины виноватые» А.Островского, Омелько – «Мартын Боруля» И.Карпенко-Карого, Гильманов – «Минникамал» М.Амира, Сиразетдин – «Банкрот» Г.Камала, Яков – «Последние» М.Горького, Харитонов – «За тех, кто в море» Б.Лавренёва, Полежаев – «Беспокойная старость» Л.Рахманова, Кучумов – «Бешеные деньги» А.Островского и др.

Х.Абжалилов удостоен почётных званий: заслуженного артиста Татарской АССР (1939), заслуженного артиста РСФСР (1940), народного артиста Татарской АССР (1944), народного артиста РСФСР (1950).

Созданные им образы Биктемира в «Потоках» Т.Гиззата, Ходжи в «Ходже Насретдине» Н.Исанбета, Лира в «Короле Лире» В.Шекспира делают его великим художником. Спектакли с участием Х.Абжалилова были показаны в Москве в 1957 году в рамках Декады татарского искусства и литературы. Первым в истории татарского театра Х.Абжалилов удостоен почётного звания народного артиста СССР.

Выдающимся было признано исполнение Х.Абжалиловым роли Мисбаххаджи («Без ветрил» К. Тинчурина, 1958), за которую артист в 1958 году был удостоен Государственной премии Татарстана им. Г. Тукая.

Х.Абжалилов активно участвует в общественной и культурной жизни Казани и республики: в 1941–1953 годах – председатель Татарского отделения Всесоюзного театрального общества, в 1947–1957 годах – депутат Верховного Совета ТАССР.

Х.Абжалилов скончался 18 марта 1963 года в Казани, похоронен на татарском кладбище в Ново-Татарской слободе Казани. На доме, где жил Х.Абжалилов, установлена мемориальная доска, одна из улиц Казани носит его имя.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Г.Камал исемендәге** Татар дәүләт академия театры. 2 томда. Т. 2. – Казан: Заман: Татар. кит. нәшр., 2009. – 368 б.: ил. – Әбҗәлилов Хәлил Гали улы. – Б. 16 – Текст парал. на рус.

**Арсланов М.Г.** Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. – Казан: Заман, 2014. – 584 б. – Әбҗәлилов Хәлил Гали улы. – Б. 30–32.

**Шакиров Ә.** Татарның бөек артисты Хәлил Әбҗәлилов // Мәдәни җомга. – 2016. – 30 сент. – Б. 12–14; Казан утлары. – 2012. – № 2. – Б. 165–171.

**Миңнуллин Т.** Хәлил Әбҗәлилов // Сәхнә. – 2012. – № 1. – Б. 2.

**Дунаев Н.** Хәлил Әбҗәлилов васыятьләре // Шәһри Казан. – 2012. – 11 сент. – Б. 9.

**Арслан А.** Әбҗәлиловның язмыш урамы // Мәдәни җомга. – 2006. – 6 окт. – Б. 17.

**Гыйматдинова Д.** Ул сәхнә бизәге иде // Шәһри Казан. – 2006. – 13 окт.

**Кумысников Х.** Тормыш мәктәбенең тырыш өйрәнчеге: Хәлил Әбҗәлилов язмышы һәм ул башкарган рольләр // Казан. – 1997. – № 3-4. – Б. 113–117.

**Кумысников Х.Л.** Халил Абжалилов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 192 с.

**Кумысников Х.** Прилежный ученик школы жизни: судьба и роли Халила Абжалилова // Казань. – 1997. – № 3-4. – С. 112–117.

**Ибатуллина-Гатова И.** Слава татарской сцены // Казань. – 2002. – № 3-4. – С. 23.

**2** октябрь/октября



**Идрис Туктар**
1896—1982

тууына 125 ел
125 лет со дня рождения

Язучы Идрис Ильяс улы Туктар (Туктаров) 1896 елның 2 октябрендә Уфа губернасының Уфа өязе (хәзерге Башкортстан Республикасының Благовар районы) Булышлы (Балышлы) авылында крестьян гаиләсендә туа. Бераздан алар Уралдагы Кучкар алтын приискаларына күчеп китә. Ун яше тулгач, Идрис тә приискада эшли башлый. Бер үк вакытта ул Кучкардагы өч класслы рус мәктәбендә, аннары Уфада дүрт класслы һөнәр училищесында укый. 1915 елда училищены тәмамлагач, Кучкарга кайтып, приискадагы хезмәтен дәвам иттерә. Шул елның көзендә аны патша армиясенә алалар. 1917 елның февралендә, ул фронтны ташлап, Кучкарга кайта һәм китапханәдә эшли.

1919 елда акларга каршы агитация эшләре алып баруда гаепләп, колчаклылар И.Туктарны кулга алалар, Чиләбе төрмәсенә ябып куялар, аннары үлем эшелонында Владивосток шәһәренә озаталар. Бер елдан ул кызыл партизаннар тарафыннан азат ителә.

1920 елда И.Туктар үз ирке белән Кызыл Армиягә языла, 1920–1922 елларда акгвардиячеләргә каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша.

1923–1924 елларда Чиләбе шәһәрендә – китапханә һәм клуб мөдире, аннары Свердловск шәһәрендә татар телендә

чыга торган «Коммунист» газетасы һәм «Шәпи агай» дигән көлке журналы редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли.



«Урал кыясында» альманахы. 1929 ел

1932–1935 елларда И.Туктар – Казан дәүләт педагогия институты студенты. Институтны тәмамлагач укытучы, аннары корректор хезмәтендә була.

1943 елның маенда фронтка китеп, 1945 елның октябренә кадәр артиллерия гаскәрләрендә гади солдат булып хезмәт итә, Совет Армиясе белән Германия җирләренә кадәр сугышчан юл уза.

Сугыштан соң И.Туктар ике ел Киевта яши: укытучы, китапханәче булып эшли.

1947 елның октябрендә Яшел Үзән шәһәренә кайтып, 1953 елның ахырына кадәр шәһәр Үзәк китапханәсендә китапханәче һәм мөдир вазифаларын башкара, 1953–1958 елларда күптиражлы газета редакциясендә тәрҗемәче булып эшли.

